ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# МӘҮЛА КОЛЫЙ

## ПОЭМАЛАРЫ

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

# МӘҮЛА КОЛЫЙ
## ПОЭМАЛАРЫ

**«БЕРЕККӘННӘР СЫЙФАТЫ»**
**«ХӘЛӘЛ НӘФӘКА ЭСТӘГӘННӘР СЫЙФАТЫ»**

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2011

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2
К52

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**Мәүла Колый поэмалары:** «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка
К52 эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Икенче басма. – Казан:
«Милли китап» нәшрияты, 2011. – 88 б. – («Татар археографиясе»
сериясе; 1 нче китап).

ISBN 978–5–88473–058–8

Бу җыентыкта XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колый иҗат иткән ике поэма тексты, аларның табылу тарихы һәм фәнни әһәмияте турындагы мәкаләләр тупланды.

ISBN 978–5–88473–058–8

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2

© Мәрданов Р.Ф., 2011
© «Милли китап» нәшрияты, 2011

## «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕ ТУРЫНДА

Археография дигән сүз әйтелгәч, иң әүвәл аның мәгънәсен искә төшереп китик. Археография – тарих фәненең бер тармагы. Грек телендә *архео* – борынгы, *графо* – язам дигәнне белдерә. Археография язма документларны, кулъязма истәлекләрне туплау, тасвирлау, өйрәнү һәм матбугат мәйданына чыгаруны үз эченә ала. Тарихның археографиядән аерылгысыз тагын бер тармагы – палеография. Грекча *палайос* – борынгы, *графо* – язам. Палеография – кулъязма чыганакларның тарихи үсештәге үзенчәлекләрен өйрәнә. Палеография язу материалын, язу билгеләрен һәм төрләрен, язу коралларын, кулъязмаларның бизәлешен, язу караларын һәм буяуларын, кәгазьләрдәге су билгеләрен, штемпельләрне, кәгазьнең форматын һәм кулъязма китап тышлыкларын өйрәнә. Алга таба археография һәм палеография терминнары еш кулланыласы булганга, монда төп билгеләмәләренә тукталу кирәк дип табылды.

Татар археографиясе дигәндә без татар кулъязма истәлекләрен – татарлар тарафыннан иҗат ителгән яки күчереп язылган, татарлар укып файдаланган, гомумән, татар халкының белем-мәгърифәтенә хезмәт иткән, татар җирлегендә сакланган язма ядкәрләрне күздә тотабыз. Татар кулъязма истәлекләрен туплау, өйрәнү һәм текстологик тикшеренүләрнең бай тарихы бар. Бу тарих шушы өлкәдә армый-талмый күп еллык хезмәт куйган галимнәребез Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан нигезле итеп өйрәнелгән[1]. Татар археографиясенең кайбер мәсьәләләрен башка галимнәр дә тикшерде.

Археография – күпкырлы гыйльми әзерлек, сабырлык һәм даими тырышлык таләп итә торган мавыктыргыч фәнни юнәлеш. Та-

[1] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – Тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – 463 б.; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – 270 б.; Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – 400 б.

тар кулъязмалары 1920 нче еллар ахырына кадәр гарәп хәрефләре белән язылганлыгын исәпкә алганда, мәсьәләнең никадәр катлаулы булуы тагын да аңлашылыр. Чөнки гарәп, фарсы, госманлы төрек телләрен белү, Ислам дине тәгълиматыннан яхшы ук хәбәрдар булу белән берлектә, гарәп язуының палеографик һәм каллиграфик серләрен аңлау да зарур. Татар язма истәлекләренең фәнни өйрәнелгән хәтлесе бер өлеш булса, өйрәнелмәгән кадәресе йөзләгән өлеш күбрәк дияргә мөмкин. Халкыбызның тупланган язма байлыгы дистә меңнәрне тәшкил итә, тик хәзерге вакытта шул мирасны тирәнтен өйрәнүчеләр бер дистәгә дә җыелмый. Милли фәнебезнең бу мөһим тармагы шундый халәттә. Ә өйрәнелмәгән кулъязма ядкәрләрдә мәдәниятебез тарихы өчен билгесез, ачылмаган күпме серләр, никадәрле фәнни яңалыклар ята.

Татар кулъязма истәлекләре фәнни китапханәләрдә һәм музейларда саклана. Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге – шундый оешмаларның иң яшьләреннән берсе. Хәзерге вакытта анда тупланган төрки-татар, гарәп һәм фарсы телләрендәге кулъязмалар дүрт меңгә якын берәмлекне тәшкил итә. Бу бүлекнең оештырылуы һәм анда кулъязмалар туплау, өйрәнү тарихы матбугатта даими яктыртылып килде[2].

---

[2] Мәрданов Р. Тарих берәмтекләп җыела // Татарстан яшьләре. – 1991. – 8 гыйнв.; Мәрданов Р. Онытмыйк күркәм гадәтләрне // Кызыл таң (Уфа). – 1991. – 6 март; Мәрданов Р. Күркәм гадәтләребезне яңартыйк // Өмет (Ульяновск). – 1991. – 11 апр.; Шул ук // Саба таңнары. – 1991. – 16 апр.; Шул ук // Ильич юлы (Биектау). – 1991. – 24 апр.; Шул ук // Халык чишмәсе (Пермь). – 1992. – Март; Мәрданов Р. Утыз беренче елларда // Татарстан яшьләре. – 1991. – 28 май; Мәрданов Р. Рухи җәүһәрләр эзеннән // Ватаным Татарстан. – 1993. – 12 март.; Мәрданов Р. Якташларның якты ядкаре // Яңарыш (Ижевск). – 1993. – Дек. (№30); Мәрданов Р. Татарстан Милли китапханәсендә татар кулъязма һәм басма китапларын эзләү, туплау һәм өйрәнү эшенең торышы: доклад тезислары // Китапка хитаб: татар басма китабының 270 еллыгына багышланган фәнни-практик конференция материаллары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б. 61–66; Мәрданов Р. Татар китабы тарихыннан // Яңарыш (Ижевск). – 1994. – 4–17 апр.; Мәрданов Р. Серле китап, кулъязмалар / Әңгәмәдәш – Энже Гәрәева // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 13 май; Мәрданов Р. Сирәк кулъязмалар ишәя // Мәдәни җомга. – 1995. – Июль (№2); Мәрданов Р. Кукмара төбәге тарихыннан кайбер сәхифәләр // Хезмәт даны (Кукмара). – 1995. – 23, 27, 30 сент.; Мәрданов Р. Борынгы язмалар ни сөйли // Хезмәт (Балтач). – 1996. – 6 апр.; Мәрданов Р. Мирасны саклау – гомуммилләт эше // Татар иле. – 1996. – Май (№18); Мәрданов Р. И Казан арты, сагынып кайттым сине

Кулъязма истәлекнең төп әһәмияте – аның бердәнбер булуында. Алар кыйммәтле документаль чыганаклар, заман шаһитләре. Кайбер текстларның яисә әсәрләрнең берничә яисә күбрәк күчерелмәләре булса да, алар һәрберсе үзенчәлекле һәм кабатланмас. Кулъязма истәлекләрне җыйнау белән бергә, аларны өйрәнү һәм

тагын да мин!.. // Мәдәни җомга. – 1996. – 3 май; Мәрданов Р. Якутлар табыладыр вакыт белән... // Бердәмлек (Самара). – 1996. – 2–8 июль; Мәрданов Р. Изге мирасны саклау – гомуммилләт эше // Туган як (Сергач). – 1996. – 27 июль; Шул ук // Хезмәт даны (Кукмара). – 1996. – 10, 14 авг.; Шул ук // Бердәмлек (Самара). – 1996. – 20–26 авг.; Шул ук // Авангард (Чуашстан, Батыр р-ны). – 1997. – 1, 3 июль; Мәрданов Р., Һадиев И. Китапларда – халкым язмышы / Әңгәмәдәш – Мәдинә Нуруллина // Мәдәни җомга. – 1996. – 1 окт.; Мәрданов Р. Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә 5 ел // Китапханә хәбәрләре=Библиотечный вестник. – 1997. – №2. – Б. 5–7; Мәрданов Р. Тарихи язмалар эзеннән // Хезмәт даны (Кукмара). – 1997. – 12 февр.; Мәрданов Р. Энҗе-алмаслар югалмас... // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1997. – №3/4. – Б. 17–22; Мәрданов Р. Изге мирасны саклау – милләт эше // Әгерҗе хәбәрләре. – 1998. – 3 февр.; Мәрданов Р. Ижау мәчете тарихыннан // Әгерҗе хәбәрләре. – 1998. – 28 июль; Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп… // Китапханә хәбәрләре=Библиотечный вестник. – 1999. – №1 (7). – Б. 25–26; Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – №5/6. – С. 81–82; Марданов Р. Фрагменты из истории Ижевской мечети // Саф Ислам. – 2000. – 28 апр.; Миңнуллин Җ., Мәрданов Р. Мирас бөртекләп җыела // Казан утлары. – 2000. – №9. – Б. 182–185; Мәрданов Р. Шиһабетдин Мәрҗани мирасына бәйле кайбер яңа табышлар // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2000. – №3/4. – Б. 184–185; Мәрданов Р. Кыйммәтле кулъязма // Китапханә хәбәрләре=Библиотечный вестник. – 2001. – №1. – Б. 36; Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре=Библиотечный вестник. – 2002. – №1. – Б. 14–19; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 125–137; Мәрданов Р. Хөсәен Фәезхановның яңа табылган кулъязмалары // Туган як (Сергач). – 2004. – 4 июнь; Марданов Р. Национальные сокровища: Сбережение // Татарский мир=Татар дөньясы (Москва-Мәскәү). – 2005. – Январь (№23–24); Мәрданов Р. «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» // Казан утлары. – 2005. – №7. – Б. 164–166; Мәрданов Р. Хөсәен Фәезхановның яңа табылган «Казан ханлыгы» хезмәте турында // Мәйдан. – 2005. – №7. – Б. 99–102; Мәрданов Р. Хөсәен Фәезхановның яңа табылган кулъязмалары // Источники и исследования по истории татарского народа: материалы к учебным курсам в честь юбилея академика АН РТ М.А.Усманова / сост. Д.М.Усманова, Д.А.Мустафина. – Казань: Казанский государственный университет, 2006. – С. 466–469; Мәрданов Р. Мәрҗани–Фәезханов хезмәттәшлеге: яңа фактлар // Казан утлары. – 2007. – №3. – Б. 136–140; [Марданов Р.]. Археографические памятники // Кукморский край. – Казань: ИД «Новости МИРА», 2008. – Серия «Регионы РФ». – С. 58–63. *(Барлыгы 42 публикация).*

текстларын әзерләп бастыру, шул рәвешчә галимнәргә һәм җәмәгатьчелек игътибарына ирештереп, фәнни әйләнешкә кертү – бүлек эшчәнлегенең төп максатларыннан иде. Мөмкинлекләребезгә күрә, бу бурычыбызны үтәп килергә тырыштык. Татарстан Милли китапханәсендәге кулъязма истәлекләрнең текстларын аерым китап рәвешендә, фәнни җыентыкларда яисә журнал-газета битләрендә бастыруга игътибар бирдек[3], шулай ук конференцияләрдә докладлар сөйләнде[4], әледән-әле күргәзмәләр оештырылды, радио һәм теле-

---

[3] Мәрданов Р. Бер мең дә тугыз йөзләрдә утыз беренче елларда... // Әдәби мирас. 2 китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 69–74; Сибгатуллин-Бубый Габдулла. Татар дөньясы / төз., җыентыкны басмага әзерләүче, кереш һәм искәрмәләрне язучы Р.Мәрданов. – Казан: Заман, 1995. – 92 б.; Шәрипов Мөхәммәдгали. Гүрләргә керде безнең башлар: («Контрреволюционер мулла» язмалары) / текстны журналга әзерләүче Р.Мәрданов // Мирас. – 1996. – №№1–6; Мәрданов Р. Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар // Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 160–171; Сагындыра иде Кукмара / гамәлдәге татар язуына күчерүче Р.Мәрданов // Хезмәт даны (Кукмара). – 1997. – 25, 29 гыйнв.; 5 февр.; Мөстәкыймов И., Мәрданов Р. Пугачев күтәрелеше тарихыннан бер чыганак // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1998. – №3/4. – Б. 220–224; Мәрданов Р. «Язылды бу язу 1756 елда...» // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2002. – №1/2. – Б. 16–18; Мәрданов Р. Кырым сәяхәтнамәсе // Мәйдан (Яр-Чаллы). – 2003. – №1. – Б. 106–114; Мәрданов Р. Кыйммәтле ядкәрләр: (Г.Курсавиның тууына 230 ел) // Казан утлары. – 2006. – №11. – Б. 174–175.

[4] Мәрданов Р. Казан арты төбәгендәге археографик табышлар: доклад тезислары // Заказанье: проблемы истории и культуры. – Казан: Заман, 1995. – Б. 145–147; Мәрданов Р. Татарстан Милли китапханәсендә археография эшенең торышы һәм бурычлары: доклад тезислары // Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре. – Казан, 1995. – Б. 15–17; Марданов Р. Новые материалы из творческого наследия Мавля Кулый: тезисы доклада // Казанское Востоковедение: традиции, современность, перспективы: тезисы и краткое содержание докладов международной научной конференции, 10-11 октября 1996 г. – Казань, 1997. – С. 33; Марданов Р. История татарской книги: тезисы доклада // Духовная культура финно-угорских народов: история и проблемы развития: материалы международной научной конференции, Глазов, 19–21 ноября 1997 г. Ч. I: Языкознание, фольклор и литературное краеведение; библиотека–книга–читатель. – Глазов, 1997. – С. 103–105; Мәрданов Р. Мәрҗани китапханәсенә бәйле яңа мәгълүматлар // Мәрҗани: Тарих һәм хәзерге заман: мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Мастер Лайн, 1998. – Б. 116–120; Мәрданов Р. Хөсәен Фәезхановның яңа табылган «Казан ханлыгы» хезмәте турында // Проблемы истории Казани: современный взгляд: сборник статей. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2004. – С. 216–220.

видениедә чыгышлар ясалды. Мәкаләләребездә һәм чыгышларыбызда татар археографиясенең актуаль мәсьәләләре (шул исәптән кадрлар җитештерү) турындагы фикерләребезне дә белдереп килдек. Ниһаять, татар кулъязма мирасын өйрәнү һәм пропагандалауның мөстәкыйль басма серия рәвешендәге нәүбәте дә җитте.

«Татар археографиясе» дип аталган бу махсус сериянең төп максаты – Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар бүлегендә саклана торган тарихи, әдәби һәм башка язма истәлекләрнең текстларын басмага әзерләп нәшер итү. Эчтәлеге һәм күләме ягыннан һәр басма төрлечә булыр. Алар тәгаен бер кысаларга гына буйсынырлар дигән чикләүләр куелмый. Чөнки без өйрәнеп, фән әһелләренә һәм җәмәгатьчелеккә тәкъдим итәргә ниятләгән материалларның төрлелеге аларны катгый бер калыпка салу мөмкинлеге бирми. Һәрхәлдә, дөнья күрәчәк басмалар сериянең исеменә туры киләчәк. Нинди текстлар бастырырга җыенуыбызны гомумиләштереп әйтсәк, алар: әдәби һәм тарихи ядкәрләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре, сәяхәтнамәләр, хатлар, документлар һәм башка төр кулъязмалар булачак. Шулай ук кулъязмалар тасвирламасы, татар палеографиясе буенча практик ярдәмлек, археографиягә багышланган мәкаләләр җыентыгы да эшләргә уйлыйбыз. Кайбер әсәрләр үзләре мөстәкыйль китапчыкны тәшкил итсә, башкалары тематика ягыннан берләштерелгән җыентыклар булыр дип ниятләнә.

Борынгырак текстларны бастырганда транслитерация рәвешендә бирү һәм кулъязма истәлекнең язылыш үзенчәлекләрен төгәлрәк чагылдыру максатында хәзерге татар алфавитында булмаган өстәмә «қ» (къ) һәм «ғ» (гъ) хәрефләрен бирү күздә тотыла. Сакланыш дәрәҗәсе мөмкинлек биргәндә төп чыганакның күчермәсе – факсимилесе дә бастырылачак.

Татарстан Милли китапханәсендәге кулъязмалардан тыш башка фәнни оешмалардагы: китапханә, архив, музейлардагы һәм шәхси куллардагы кулъязма истәлекләр дә, тематикасына күрә, гомум кагыйдәләр кысасында һәм алдан килешенү нигезендә, бу сериядәге басмаларга кертелүе ихтимал.

2004 елда нәшер ителгән «Мәрҗани китапханәсе» исемле җыентык[5] бу сериянең башлангычы итеп саналырга хаклы. Ә «Татар археографиясе» дигән махсус серия исеме куелган беренче басма буларак – Татарстан Милли китапханәсенең иң кыйммәтле язма хәзинәләреннән Мәүла Колыйның фән дөньясында әлегә бердәнбер күчермәдә билгеле, барлыгы 304 шигъри юлдан гыйбарәт поэмалары нәшер ителә. Поэмаларның текстларын беренче тапкыр 1996 елда «Казан утлары» журналында бастырган идек. Бу басмада элек киткән кайбер хаталар төзәтелде.

[5] Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиографик җыентык / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: Милли китап, 2004. – 122 б.

# МӘҮЛА КОЛЫЙ СҮЗЛИ, ДУСЛАР...

Мәүла Колый – XVII йөзнең икенче яртысында иҗат иткән күренекле татар әдибе. Ул Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф кебек фикер ияләренең рухи бакчаларыннан азык алып, үз шигъри дөньясын тудырган олы шагыйрь.

Татар әдәбияты тарихында Мәүла Колый иҗаты өйрәнелә башлаганга 85 ел вакыт үтте. Аның әсәрләре табылу турында беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1926 елгы 9 апрель санында Фазыл Туйкә хәбәр итә[1]. Шул вакыттан алып Мәүла Колый шигырь-хикмәтләренең яңадан-яңа күчермәләре табыла һәм өйрәнелә. Шагыйрьнең иҗатын төрле елларда барлап, аны фәнни өйрәнүгә Ф.Туйкә, Габдрахман Сәгъди, Латыйф Җәләй, Шакир Абилов, Хәй Хисмәтуллин, Камил Дәүләтшин, Гайсә Хөсәенов, Марсель Әхмәтҗанов, Мәсгуд Гайнетдин кебек галимнәр зур өлеш керттеләр, Мәүла Колыйның кем булуы турында фикер-фаразлар белдерделәр, әдипнең нәсел шәҗәрәсен һәм тормыш юлын ачыкларга омтылдылар[2].

---

[1] Туйкә Ф. Борынгы Болгар шагыйре // Кызыл Татарстан. – 1926. – 9 апрель (№81); Ф.Туйкәнең бу мәкаләсе «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителгән китапта хәзерге татар язуына күчерелеп яңадан басылды (Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Э.Ханнанова-Галимҗанова. – Казан: Рухият; Җыен, 2007. – Б. 169–170).

[2] Сәгъди Г. Беренче дәвер татар әдәбиятыннан яңа материаллар // Мәгариф. – 1927. – №4. – Б. 64–72; Туйкә Ф. Тузанлы шүрлекләрдән: (әдәбият тарихына материаллар) // Безнең юл. – 1928. – №9. – Б. 42; Җәләй Л., Байков С. Әдәбияттан дәреслек-хрестоматия: 8 класс өчен. – Казан, 1940. – Б. 8–21; Абилов Ш. Шагыйрьнең исеме Мәүла Колыймы әллә Меллаголмы? // Совет әдәбияты. – 1958. – №11. – Б. 107–110; Хисмәтуллин Х. Шагыйрь Мәүла Колый иҗаты // Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 480–503; Давлетшин К.С. Творчество поэта XVII века Мавля Кулыя: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Казань, 1971. – 28 с. (КГУ); Дәүләтшин К. Мәүла Колый хикмәтләренең поэтик үзенчәлекләре: (язылуга 300 ел тулу уңае белән) // Совет мәктәбе. – 1971. – №2. – Б. 22–24; Абилов Ш. Мәүла Колый хикмәтләренең яңа кулъязмасы // Казан утлары. – 1971. – №6. – Б. 147–151; Хөсәенов Г. Юллар уңышлы булды // Кызыл таң (Уфа). – 1974. – 23 июль; Дәүләтшин К. Мәүла Колый хикмәтләренең поэтикасы һәм тел

Мәүла Колый әсәрләре тел һәм иҗтимагый фикер үсешендәге үзенчәлекләре ягыннан билгеле бер кадәр тикшерелгән. Шулай ук аның шактый әсәрләре русчага тәрҗемә ителеп, башка милләт укучыларына да тәкъдим ителгән[3].

Моңарчы кат-кат расланганча, Мәүла Колый иҗатының нигезе суфыйчылык рухы белән сугарылган. Шул ук вакытта, башка татар суфый әдипләренә хас булганча, Мәүла Колый әсәрләрендә җирле традицияләр һәм дөньявилык идеяләре чагылыш тапкан. Тулаем алганда, аның иҗат нигезен тәшкил иткән суфыйчылык Ислам дине кысаларындагы гаять катлаулы фәлсәфи бер тәгълимат икәнлеген истә тотарга кирәк.

Мәүла Колыйның тормыш юлы хакындагы мәгълүматлар бөтенләй билгесез иде диярлек. Марсель Әхмәтҗанов, шагыйрьнең иҗатына, шул чор документларына, шәҗәрәләргә һәм рива-

---

үзенчәлекләре // Татар теле һәм әдәбияты. 5 китап. – Казан, 1976. – Б. 203–214; Абилов Ш., Дәүләтшин К. Мәүла Колый иҗаты // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Т.1: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 366–385; Әхмәтҗанов М. Мәүла Колый кем ул? // Совет мәктәбе. – 1986. – №10. – Б. 17–19; Әхмәтҗанов М. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. – Казан: Мәгариф, 1999. – Б. 52–54; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 77–83; Мәүла Колый. Хикмәтләр / төз., иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М.Гайнетдин. – Казан: «Иман» нәшр., 2001. – 136 б.; Дәүләтшин К. Тарих сынавын үткән шигърият // Мирас. – 2001. – №5. – Б. 18–21; Мәүла Колый. Хикмәте хаким... / текстны әзерләүче К.Дәүләтшин // Мирас. – 2001. – №5. – Б. 22–34; №6. – Б. 36–48; №7. – Б. 26–35; №8. – Б. 5–18; №9. – Б. 12–23; №11. – Б. 5–16; 2002. – №1. – Б. 15–29; №2. – Б. 5–18; Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2004. – 319 б.

[3] Колый М. Поучения о земледелии; О бродягах: (стихи) / пер. с татар. Р.Моран // Моран Р. Выбор: стихотворения. Страницы татарской поэзии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1968. – С. 61–63; Колый Мэвла. О любви, страсти и нравственности: (стихи) / пер. с татар. Р.Моран // Песнь любви: любовная лирика народов СССР. Т. II. – М.: Молодая гвардия, 1972. – С. 157; Колый Мэвла. Хикметы. На этот мир ты не смотри // Поэзия народов СССР IV–XVIII вв. – М.: Художественная литература, 1972. – С. 490–492. – (Б-ка всемирной литературы); Каюмова Г.В. Древние глагольные формы в хикметах Мавля Кулыя // Гуманитарные науки и их закономерности. Ч. II. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. – С. 65–72; Мухаметдинов Р.Ф. Социально-философские мотивы в творчестве Мавля Кулый // Из истории формирования и развития свободомыслия в дореволюционной Татарии. – Казань, 1987. – С. 21–32.

ятьләргә нигезләнеп, Мәүла Колый биографиясен беркадәре тасвирлады[4]. Галим туплаган мәгълүматларга караганда, Мәүла Колый (кайбер шигырьләрендә язылганча, «Меллагол кол») исеме белән билгеле шагыйрьнең чын исеме Бәйрәмгали Колыев (Бимкә суфый) булган икән. Ул XVII йөз урталарында Казан өязендәге Чыты авылында (хәзерге Питрәч районында) дөньяга килгән. Казанда мәдрәсәдә укыган. Аның исеме XVII гасыр ахырында хөкүмәт һәм татарлар арасындагы гауга-низагларга бәйләнешле документларда да телгә алынган. Казан ягындагы төрле татар авыллары крестьяннары 1678 елда Мәүла Колый (Бәйрәмгали Колыев) җитәкчелегендә Биләр шәһәре хәрабәләре янына күчеп урнашканнар. Патша хөкүмәте, әлбәттә, бу хәл белән ризалашмаган һәм 1699 елда, Пётр Беренче фәрманы буенча, татарлар ул җирләрдән куылганнар. Мәүла Колый иптәшләре белән Шушма буена, Иске Иштирәк авылына (хәзерге Татарстанның Лениногорск районы җирлегендә) барып урнашкан.

Марсель Әхмәтҗанов табып ачыклаган дәлилләр буенча Мәүла Колыйның тормыш юлы шул рәвешчә күзаллана. Бу мәгълүматлар, «Татар поэзиясе антологиясе»нең яңа басмасында да (чыганагы күрсәтелмичә) тулаем урын алган. Антологиядә шагыйрьнең әсәрләренә шактый киң урын бирелгән[5].

Филология фәннәре докторы М.Әхмәтҗанов Мәүла Колыйның биографиясе турындагы үз фикерләрен башка хезмәтләрендә дә кабатлады һәм дәлилләр китереп аңлатты[6]. Галим, филология фәннәре докторы Х.Миңнегулов «аерым исбатлаулар буенча» дигән искәрмә белән М.Әхмәтҗанов мәгълүматын мәктәп дәреслекләренә кертте[7]. Әмма әдәбият белгече, филология фәннәре докторы Мәсгуд Гайнетдин Мәүла Колыйның биографиясе турындагы

---

[4] Әхмәтҗанов М. Мәүла Колый кем ул? // Совет мәктәбе. – 1986. – №10. – Б. 17–19.

[5] Татар поэзиясе антологиясе. I китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 179–187.

[6] Әхмәтҗанов М. Дастаннар ватаны... – Б. 52–54; Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы. – Б. 77–83.

[7] Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Әдәбият: татар урта гомуми белем мәктәпләре һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. – Тулыл. икенче басма. – Казан: Мәгариф, 1998. – Б.151.

М.Әхмәтҗанов расламалары белән ризалашмыйча, аларны кире каккан иде[8]. Шулай да Мәүла Колыйның биографиясенә караган мәгълүматны галимнәрнең күпчелеге кабул итте һәм ул Татар энциклопедиясендә дә урын алды[9]. Мәүла Колый иҗатын җентекләп өйрәнгән галим Камил Дәүләтшин М.Әхмәтҗанов фикерләре белән тулаем килешә[10].

Мәүла Колый хикмәтләренең кульязма күчермәләре Казан, Уфа һәм С.-Петербург шәһәрләрендәге гыйльми оешмаларда саклана. Аның әсәрләренең күчермәләре татарлар яши торган төбәкләрдә, сирәк булса да, хәзер дә табылып тора. Мәүла Колый иҗатына бәйле табышларның соңгыларыннан берсе – поэмалары табылу – татар әдәбияты тарихы өчен зур әһәмияткә ия булды. Мәүла Колыйның фәнгә бөтенләй мәгълүм булмаган яңа әсәрләренең күчермәләре табылгач, хикмәтләр авторы сыйфатында билгеле булган Мәүла Колыйның поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыкланды.

Әгерҗе районының Яңа Аккуҗа авылында яшәгән Фазлетдин ага Габдрахмановтан (1908–1995) әдипнең ике поэмасы теркәлгән кульязма җыентык 1990 елның гыйнварында[11] безнең тарафтан алынган иде. Ул хәзер Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «606 т» шифры белән саклана. Сүз уңаеннан шуны искәртеп китик, археограф-галим Марсель

[8] Мәүла Колый. Хикмәтләр / төз. ... М.Гайнетдин. – Б. 6–11; Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Б. 60–66.

[9] Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 4: М–П. – Казань: Ин-т Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. – С. 6.

[10] Дәүлетшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: уку кулланмасы. – Уфа: РИЦ Баш ГУ, 2010. – Б. 12–13.

[11] Бу кульязма җыентыкны Татарстан Милли китапханәсенә эшкә урнашканчы ук табып алган идем. 1984–1990 елларда туган төбәгем Әгерҗе районы авылларында кульязма истәлекләр җыю белән шактый шөгыльләндем. Аларның бер өлешен Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсенә, кайберләрен КДУның Фәнни-археографик лабораториясенә тапшырдым. Зур күпчелеген исә эшкә урнашканнан соң Татарстан Милли китапханәсенә бирдем. Китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә мин тапшырган алтмыштан артык кульязма ядкәрләрнең төрки-татар телендәге 48 берәмлеге анда эшли башлаганчы (1990 елның августына кадәр) җыйналган иде.

Әхмәтҗанов 1978 елда шул ук авылдан XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы күчермәсен тапкан иде[12].

Мәүла Колый поэмалары язылган кулъязма җыентык Россия һәм Европа кәгазьләренә язылган, һәр битнең зурлыгы 10х16 см. Ул XX гасыр башында Казанда басылган «Һәфтияк шәриф» китабының тышлыгы эченә урнаштырылган. Җыентык ахырындагы унбер кәгазьдә (62а–72б) Мәүла Колыйның ике поэмасы язылган. Ике әсәр дә җыентыкка гарәп язуының шикәстә элементлары кушылган тәгъликъ төре белән теркәлгән. Бер биттәге текстның зурлыгы 7,5х13,5 см мәйданны били. Битләрдә шигъри юлларның саны төрлечә. Беренче әсәр 62а кәгазьдә – унике юл, 62б–64б һәм 66а–67а кәгазьләрдә унөчәр юл, 65а–65б һәм 68а–69б кәгазьләрдә ундүртәр юл, 67б һәм 70а кәгазьләрдә унбишәр юл итеп язылган. 70б кәгазьдә беренче поэманың ахыргы сигез юлы һәм икенче поэманың исеме белән башындагы дүрт юлы язылган. Икенче әсәрнең дәвамы 71а кәгазьдә ундүрт юл, 71б–72б кәгазьләрдә уналтышар юл язылган.

Җыентыкның 1а–61б кәгазьләрендә төрле дини мәсьәләләргә караган язмалар, Рамазан аена багышланган шигъри әсәр һәм бүтән мәгълүматлар теркәлгән. (Алар турында бу китап ахырында махсус тасвир язылды). Кулъязманың Бәдшәл авылында[13] (44а кәгазь) Мортаза атлы кеше кулы белән 1754 елда (61а кәгазь) язылганлыгы күрсәтелгән. Җыентыктагы барлык текстлар да коңгырт сары төстәге кара белән бер үк кеше тарафыннан язылган. Кулъязма җыентыкның саклануш дәрәҗәсе уртача. Күп урыннарында карасы уңган, кәгазе зарарланган.

Мәүла Колый әсәрләре теркәлгән кулъязманың аерым битләре җуелганлыктан, поэма текстлары да өлешчә генә сакланган. Беренчесе (62а–70б кәгазьләрдә) сюжет һәм эчтәлек ягыннан шактый тулы, барлыгы 238 шигъри юлдан (118 тулы һәм ике яртышар бәйттән) гыйбарәт. Иң башындагы битләре – әсәрнең исеме һәм текстның башлам өлеше (якынча 1-2 бит күләмендә) сакланмаган булса да, төп һәм ахыргы өлешләре тулы, фәкать әсәрнең уртасындарак, кулъязмадагы берничә бит җуелу сәбәпле, өзеклек бар. Әсәрнең

[12] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. – 1995. – №11. – Б. 51-52.
[13] Бу авыл хакында мәгълүматлар табылмады.

ахырында (113 нче бәйттә) «Береккәнләр сыйфатын әйдем сезә...» (ягъни, берләшкәннәр, бердәмнәр сыйфаты) дип поэманың исеменә дә ишарә ителә. Аннан соң (118 нче бәйттә):

«Әй, Ходайа, гасый җафи Мәүла Колый,
Рәхмәтеңлә сән биргел коллык йулый...»

– дип, әсәр авторының исеме күрсәтелгән. Поэманың исемен һәм авторын әсәр ахырында белдерү, авторның үз-үзен түбәнсетеп «гасый җафи» (ягъни, гөнаһлы) дип эндәшеп тәмамлавы – суфыйчылык әдәбияты өчен хас күренеш. Мондый алымны Колыйның рухи остазлары булган Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Мәүла Колыйның үз шигырь-хикмәтләрендә дә андый алым кулланылган. Мәсәлән, остазы Мелла Мамайга багышланган хикмәтенең бер күчермәсендә бетем өлеше «Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар», дип тәмамлана.

Икенче поэмасының, кызганычка каршы, 33 бәйттән торган башлангыч өлеше генә (70б–72б кәгазьләр, барлыгы 66 шигъри юл) сакланган, төп һәм бетем өлешләре юк. Шулай да, әсәрләрнең теле, идея-тематик үзенчәлекләренең якынлыгы җәһәтеннән караганда, ике поэманы да бер үк автор иҗат иткәнлеге бәхәссез. Хәтта аларның исемнәре дә бер-берсенә аваздаш: беренчесе «Береккәннәр сыйфаты» рәвешендә булса, икенчесе «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» («Хәләл байлык теләүчеләр сыйфаты»). Текстлардан күренүенчә, һәр сыйфат сюжет ягыннан мөстәкыйль бер әсәр рәвешендә гәүдәләнә. Мәүла Колыйның мондый «сыйфатлау»лар рәвешендә язылган әсәрләре тагын да булып, алар бер циклны тәшкил иткәндер дип тә фаразларга мөмкин.

«Береккәннәр сыйфаты» поэмасының кыскача эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт.

Бер ир белән хатын, үзара киңәш-табыш иткәннән соң, фани дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, тыныч урынга китеп, тормышларын тулаем Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга, ахирәт тормышына ихластан әзерләнүгә багышларга карар итәләр. Бер тауга барып кечкенә генә торак һәм гыйбадәтханә төзиләр, шунда гомер кичерә башлыйлар. Хак Тәгалә юлыннан тайпылмыйча, намаз укып, ураза тотып, 60 ел яшәгәч, боларга Иблис вәсвәсә сала. Иблис ирнең

гыйбадәт белән генә утыру фикерен чуалта. Аллага биргән антларын бозу булса да, ир белән хатын дөнья күрергә дип чыгып китәләр. Бер шәһәр янындагы чишмә буенда тукталалар. Ире ипи алу өчен шәһәргә юнәлә. Аннан кайтышлый ул бер мәһабәт сарай һәм сарай эчендәге искиткеч гүзәл хан кызын күреп туктала. Икесенең дә күңелләрендә гыйшык уты кабына. Хатыны янына кайткач, ир хәлне аңлатып бирә.

Шушы урында, берничә бит төшеп калу сәбәпле, текстка өзеклек кергән һәм әсәрдә тасвирланган кайбер хәлләр безгә билгесез кала. ...Ниндидер вакыйгалардан соң хан кызы белән ирне «тотып алалар» һәм зинданга ябалар. Бичара хатын кайтмаган ирен эзләп сарайга килә. Иренең кайда икәнлеген ачыклагач, башын-йөзен ике бөркәнчек белән каплап, ике табак аш (ризык) алып зинданга бара. Зиндан сакчысының күңелен бер табак аш белән яулап алып, зинданда ябылган кешемә ризык ашатыйм дип, эчкә үтә. Башындагы бер бөркәнчекне хан кызына яптыра һәм аңа буш табакны да биреп, чыгарга куша. Аулак җирдә табакларны ташлагач, сараеңа кайт та тыныч кына йөр дип, кызны өйрәтеп җибәрә.

Кызының ниндидер ят ир белән тотылуыннан хурланган, ачуыннан ярсыган хан җәлладка тоткыннарны китерергә куша. Зинданчы аларны тиз генә хан янына алып килә. Шактый гына аңлашканның соңында, хатын йөзеннән бөркәнчеген алгач, боларның ир белән аның хәләл хатыны икәнлеген күреп, хан һәм җәллад хәйран калалар. Шул рәвешчә, ханның йөзе «ак» булып кала, ир белән хатын да җәзадан исән-сау котылалар. Өстәвенә, хан аларга күп итеп малбайлык бирә. Ир һәм хатын әүвәлгечә гыйбадәт белән тыныч гомер кичерүләрен дәвам итәләр.

Автор бу поэмасын береккәнлек, ягъни бердәмлек аркасында гына бәладән котылып, иминлеккә ирешергә мөмкин дигән фикер белән йомгаклап куя. Шулай итеп, әсәр укучыларны бердәмлеккә өндәп, «берлектә – көч» дигән рухта тәмамлана.

Әсәрнең сюжеты мавыктыргыч һәм чишелеше оста корылган. Автор әсәрдәге хәлиткеч вазыйфаны хатынга йөкләгән. Аның кыюлыгы һәм зиһене белән Мәүла Колый четерекле мәсьәләне уңай хәл итә. Нәтиҗәдә, «бүреләр дә тук, сарыклар да исән» булып кала.

Әсәрнең идея-тематик ягы кешелек дөньясында һәрвакыт актуаль булган бердәмлек мәсьәләсенә нигезләнгән.

Кулъязма җыентыктагы икенче әсәр – «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» поэмасының аз өлеше генә сакланганлыктан, аның эчтәлеген тулаем күзаллау мөмкин түгел. Тик текстының сакланып калган фрагменты буенча фикер йөрткәндә, Мәүла Колыйның бу поэмасы да шактый күләмле һәм гыйбрәтле сюжетка корылган булуы чалымлана.

Мәүла Колый поэмалары шигъри төзелешләре һәм тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, шулай ук Мөхәммәдьяр әсәрләренә бик якын тора. Аларда гарәп-фарсы алынмалары чагыштырмача аз, борынгы язма төрки-татар теле формалары өстенлек итә.

XVII гасырда яшәп иҗат иткән татар шагыйре Мәүла Колыйның поэмалары табылу турында беренче мәртәбә киң җәмәгатьчелеккә «Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» дигән исем белән 1995 елның 14 декабрендә Татарстан Милли китапханәсенең 130 еллык юбилее уңаеннан оештырылган фәнни-гамәли конференциядәге чыгышымда хәбәр иткән идем[14]. Аннан соң 1996 елда «Казан утлары» журналында «Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар...» исемле кереш мәкаләбез[15] белән поэмаларның текстларын[16] да бастырып чыгарган идек. Шунда ук М.Госмановның «Тагын бер әдәби ачыш» исемле мәкаләсе[17] дә дөнья күрде. 1996 елның 10–11 октябрь көннәрендә Мәүла Колыйның бу поэмалары турында Халыкара фәнни конфе-

---

[14] Мәрданов Р. Татарстан Милли китапханәсендә археография эшләренең торышы һәм бурычлары // Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре. – Казан, 1995. – Б. 15–17.

[15] Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 160–164.

[16] Шунда ук. – Б. 164–171. Әсәрләрне журналда бастыру өчен әзерләгәндә текстологик эшкәртү буенча киңәшләрен биргән һәм аерым сүзләрнең дөрес укылышларын һәм мәгънәләрен ачыклауда академик Миркасыйм Госманов ярдәм күрсәтте.

[17] Шунда ук. – Б. 159–160. М.Госмановның бу мәкаләсе шул ук исем белән авторның «Гасырдан – гасырга» исемле җыентыгына (төз. Җ.Миңнуллин. Казан, 2004) да кертелгән (403–405 битләр).

ренциядә дә чыгыш ясадык. Бу докладның тезислары конференция материаллары тупланган русча җыентыкта басылып чыкты[18].

«Казан утлары» журналындагы мәкаләбезне болай дип тәмамлаган идек: «Мәүла Колыйның яңа табылган бу әсәрләрен киләчәктә анализлап, әтрафлы өйрәнү, әлбәттә, әдәбият һәм тел галимнәре бурычы. Безнең бурыч татар әдәбияты тарихы өчен әһәмиятле булган яңа табышны матбугат аша укучыларга җиткерү һәм галимнәр хөкеменә тапшырудан гыйбарәт. Җыеп әйткәндә, Мәүла Колый каләменә бәйле бу яңа табышларның тагын бер әһәмиятле ягы шунда ки: алар шул әсәрләрнең тулырак күчермәләрен эзләүгә һәм, шуның белән бергә, шагыйрь мирасының фән өчен моңарчы мәгълүм булмаган яңа сәхифәләрен ачуга этәргеч булып торалар»[19].

Бу сүзләр язылганнан соң күп еллар узгач та Мәүла Колыйның әдәбият фәне өчен яңалык китергән поэмалары фәнни әйләнешкә тулы дәрәҗәсендә кереп урнаштылар дип булмый. Галимнәребезнең кайберләре уңай мөнәсәбәтләрен гамәлләре белән расласа, күпчелек хәзергәчә битарафлык күрсәтә.

Санаулы галимнәр Мәүла Колый поэмалары турында азмы-күпме мәгълүмат бирделәр. Борынгы әдәбият белгече Хатыйп Миңнегулов мәктәпләр өчен төзелгән әдәбият дәреслегенә Мәүла Колыйның поэмалары турында «Шагыйрьнең яңа табылган әсәрләре» исемле махсус бүлекчә кертте. Бу бүлекчәдә автор, аерым алганда, болай дип яза: «Поэмаларның тел-стилендә, шагыйрьнең хикмәтләре белән чагыштырганда, архаик сүзләр һәм формалар күбрәк. Ритмик төгәлсезлекләр дә очрый. Мәүла Колый бу әсәрләрен, күрәсең, яшьрәк чакта, әдәби тәҗрибәсе азрак вакытта иҗат иткәндер, дигән фикер кала»[20]. Х.Миңнегулов шулай ук әдәбият буенча хрестоматиягә «Береккәннәр сыйфаты» поэмасының ахырындагы 16 шигъ-

[18] Марданов Р. Новые материалы из творческого наследия Мавля Кулый // Казанское востоковедение: традиции, современность, перспективы: тезисы и краткое содержание докладов международной научной конференции, 10-11 октября 1996 г. – Казань: Изд-во «ФЕСТ», 1997. – С. 33–35.
[19] Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 164.
[20] Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 156.

ри юлдан гыйбарәт өлешен урнаштырды[21]. Галим Марсель Әхмәтҗанов та үз хезмәтләрендә Мәүла Колыйның ике поэмасы табылу фактын искә алып килде[22]. Камил Дәүләтшин шагыйрьнең билгесез булган поэмалары табылуны берничә сүз белән генә әйтеп үткән иде[23].

Ә менә башка белешмә китапларда, шулай ук әдәбият белгечләребезнең Мәүла Колый турында язган әсәрләрендә һәм фәнни мәкаләләрендә шагыйрьнең поэмалары турында берни дә әйтелмәве аптыраштта калдырды. Мәсәлән, Татар энциклопедия сүзлегенең 1999 елда дөнья күргән рус телендәге басмасында, шулай ук 2002 елгы татарча басмасында да Мәүла Колыйның шигырьләре турында гына әйтелеп, поэмалары хакында бер сүз дә юк иде[24].

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнеп, татар әдәбияты тарихы буенча рус телендә 1999 елда нәшер ителгән бик мөртәбәле җыентыкта Мәүла Колыйга аерым мәкалә багышланган, шулай ук шагыйрьнең исеме бүтән мәкаләләр эчендә дә телгә алынган. Тик поэмалар иҗат иткәнлеге турында бер сүз юк[25].

Мәүла Колыйның 2001 елда басылган «Хикмәтләр» китабының кереш мәкаләсендә[26] шагыйрьнең поэмалары турында шулай ук берни әйтелмәгән. Бу кереш мәкалә галим М.Гайнетдиннең 2004 елгы мәкаләләр җыентыгына да кертелгән, тик анда да поэмалар искә алынмый[27].

---

[21] Татар әдәбиятыннан хрестоматия: татар урта гомуми белем мәктәпләре һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен / төз. Х.Й.Миңнегулов, Ш.А.Садретдинов. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 145.

[22] Әхмәтҗанов М. Дастаннар ватаны... – Б. 52; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Б. 77.

[23] Дәүләтшин К. Тарих сынавын үткән шигърият // Мирас. – 2001. – №5. – Б. 18.

[24] Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Ин-т Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – С. 332; Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: Татар энциклопедиясе ин-ты, 2002. – Б. 416.

[25] Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – 240 с.

[26] Мәүла Колый. Хикмәтләр / төз. ... М.Гайнетдин. – Казан: «Иман» нәшр., 2001. – Б. 3–11.

[27] Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Б. 60–66.

Әдәбият энциклопедиясе дәрәҗәсендәге «Әдәби сүзлек»нең (авторлары И.Рәми һәм Р.Даутов) 2001 елгы басмасында Мәүла Колый турында язылса да[28], аның поэмалары турында берни белдерелмәве шулай ук аңлашылмады. Югыйсә, бу хезмәтнең искәр–мәләрендә «Казан утлары» журналында (1996 ел, 10 нчы сан) шагыйрь поэмаларының текстлары басылганнан соң матбугатта чыккан 1997–1999 еллардагы башка әсәрләргә ишарәләр бирелгән.

Әдәбият галиме Резеда Ганиеваның татар әдәбияты традицияләре һәм багланышлары турындагы зур хезмәтендә Мәүла Колый поэзиясенә махсус бүлек багышланса да – анда да поэмалары телгә алынмаган[29]. Дөрес, бу мәкаләнең язылу елы итеп 1991 ел күрсәтелгән. Әмма, шуңа да карамастан, китап 2002 елда гына чыккач, фәндәге яңалык турында замана укучысын хәбәрдар итеп тоту өчен кереш мәкаләдә яисә астөшермәдә искәрмә бирү яраган булыр иде.

Олуг галимнәребезнең Мәүла Колый поэмаларын «күрми калу»ларына, һичшиксез, йөзләгән аклану табылырга мөмкин. Шулай ук без монда күрмәүчелек мисалларының барысын да теркәү максатын куймадык. Бары тик җитди басмаларның кайберләренә генә тукталдык. Бу – әдәби мираска карата зәгыйфьрәк мөнәсәбәтнең дәрәҗәсен күрсәтә торган бер мисал. Чыгышларымда һәм матбугатта моңарчы бу хакта әйткәләсәм дә[30] – файдасы күренмәде. Мәүла Колыйның поэмаларын табып фәнгә тәкъдим иткән кеше буларак, шагыйрьнең рухы алдында үземне бик уңайсыз хис иттем. Менә мондый күрмәмешкә салынуның төп сәбәбе – бер өлеш галимнәребезнең үзләреннән яшьрәк буын фән әһелләре табышларын танырга теләмәвеннән килә. Әлеге мөнәсәбәт нәтиҗәсендә, кызганычка каршы, Мәүла Колыйның иҗаты һәм, шуның белән беррәттән, әдәбият тарихыбыз да кимсетелә. Бу хакта, беренчедән, мәсьәләгә ачыклык кертеп китү максаты белән һәм, икенчедән, киләчәк фән әһелләребезгә гыйбрәт-сабак өчен яздык. Чын фән дөньясы мондый тар мәгънәсезлектән азат һәм өстен булырга тиеш.

---

[28] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек: элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. – Казан: Татар. китап нәшр., 2001. – Б. 171–172.

[29] Ганиева Р. Татарская литература: традиции, взаимосвязи = Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. – Казань: Изд-во КГУ, 2002. – С. 24–29.

[30] Тарихка йөз белән: Р.Мәрданов белән Х.Закиров әңгәмәсе // Мәгърифәт. – 2004. – 26 июнь.

«Татар археографиясе» сериясенең беренче китабы – «Мәүла Колый поэмалары» җыентыгы 2008 елда чыкканнан соң бераз уңай үзгәрешләр күзәтелде. Мәсәлән, иң башта Айсылу Нәҗмиеваның хәбәре чыкты[31], аннан соң Мансур Ильясовның рецензиясе басылды[32]. Китапның кереш мәкаләсе Чаллы шәһәрендә нәшер ителә торган газетага күчереп бастырылды[33]. Алты томлык Татар энциклопедиясенең рус телендә нәшер ителгән дүртенче томында урын алган Мәүла Колый турындагы мәкаләдә аның ике поэма авторы булуы, поэмаларның исемнәре аталган һәм әлеге әсәрләрнең XX гасыр ахырында өйрәнелгәнлеге турында ике җөмлә белән булса да әйтелгән[34]. «Әдипләребез» исемле мәртәбәле биобиблиографик басмада Мәүла Колыйның ике поэмасы турында өч җөмләлек мәгълүмат урнаштырылган[35]. «Китапханә хәбәрләре» журналында «Татар археографиясе» сериясендә нәшер ителгән дүрт китап, шул исәптән «Мәүла Колый поэмалары» турында кыскача игълан-тәкъдимнамә басылып чыкты[36]. Ә шагыйрьнең бөтен иҗади мирасын бергә туплап бастырган Камил Дәүләтшин үз хезмәтенең кереш мәкаләсендә М.Колый поэмалары турында язды һәм әсәрләрнең безнең беренче басмада дөнья күргән текстларын тулаем күчереп бастырды[37]. Тик шунысы кызганыч, бу китап нибарысы бер йөз данә генә чыккан. Мәгълүмат тулы булсын өчен Ч.Заһидуллина мәкаләсендә дә Мәүла Колый поэмалары искә алынуын әйтергә кирәк[38].

---

[31] Нәҗмиева А. Мәүла Колый кайтты! // Мәгърифәт. – 2008. – 8 ноябрь.
[32] Ильясов М. Әдәби ядкарьләребезне барлаганда // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2008. – №2. – Б. 231.
[33] Мәрданов Р. Мәүла Колый сүзли, дуслар // Историко-культурное наследие. – 2008. – №1 (декабрь). – Б. 13; 2009. – №2 (январь). – Б. 13.
[34] Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 4: М–П. – Казань: Ин-т Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. – С. 6.
[35] Даутов Р.Н., Рахмани Р.Ф. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда. 2 том. – Казан: Татар. китап нәшр., 2009. – Б. 64.
[36] «Татар археографиясе» сериясе, Серия «Татарская археография» // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2009. – №1 (27). – Тышл. 3 бит.
[37] Дәүлетшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: уку кулланмасы. – Уфа: РИЦ Баш ГУ, 2010. – Б. 6, 14, 41–43, 202–228.
[38] Заһидуллина Ч. Аллаһны зурлаган шагыйрь // Татарстан укытучысы. – 2010. – №3. – Б. 13–14.

***

Поэмаларның басмага әзерләнгән текстларында укылышны һәм аңлауны җиңеләйтү өчен транслитерация элементлары кулланылды. Квадрат җәяләр эчендә без өстәгән аерым хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр кульязманы күчерүче тарафыннан ялгыш төшереп калдырылган дип уйланылган фаразлардан гыйбарәт. Текстлардагы кайбер имля тотрыксызлыгы (мәсәлән, барып-баруб-барыб, килеб-килүб, ирде-иде, диб-тиб һ.б.) кульязманың үзендәгечә, үзгәрешсез бирелде. Поэмаларның текстлары тулы булмаса да, сакланган шигъри юлларына бәйт саннарын куйдык. Текстларның кульязмада кайсы биткә туры килүләре дә күрсәтелде.

Текстлардагы кайбер палеографик үзенчәлекләрне дә әйтеп китик. Ул чор кульязмаларына хас булганча, «син» хәрефенең астында һәм «уау» хәрефенең өстендә өчәр нокта куелган. «Уау» хәрефе сүз уртасында килгән кайбер очракларда ике ягындагы хәрефләргә тоташтырып язылган. ق (қаф) һәм ت (тә) хәрефләренең икешәр ноккалары кайчагында вертикаль рәвештә язылганнар. Сирәк очракларда булса да, сүз ахырындагы ى (йа) хәрефенең астында икешәр нокта куелган. ح (хә) хәрефенең астында «һәмзә»гә охшаш билге язылган очраклар да бар. Кульязма тексттагы мондый өстәмә нокталар, тамга-билгеләр гарәп язуының шикәстә һәм тәгъликъ язуларына хас. Ләкин монда санап үтелгән палеографик үзенчәлекләр кульязмада тотрыклы түгел.

Поэма текстларындагы кайбер сүзләрдә хәрәкәләр (бигрәк тә, «заммә» һәм «сәкен») куелган. «Сәкен» хәрәкәсе, хәреф өстендә язылысы урында, кайбер сүзләрнең ахырларында хәрефләр белән бер рәттә «ә» яисә «һ» хәрефе кебек язылган. Мәсәлән, «Береккәннәр сыйфаты» поэмасының 45 нче бәйтендә «Заһид» сүзенең соңгы хәрефе өстендәге «сәкен» сүз ахырындагы тагын бер хәреф рәвешендә язылганлыктан, «Заһидә» дип укылу ихтималы бар. Әмма бу очракта аның «Заһид» буларак укылышы бәхәссез.

Гомумән, поэмаларның кульязма текстында әүвәлге орфографик тотрыксызлык чагылышлары, хәреф хаталары, сүзләрне ялгыш язулар бар. Мәсәлән, төрки тамырлы сүзләрдә бер төрле үк тартык хәрефләр икешәр мәртәбә язылырга тиеш булган очракларда (*кайт-*

*ты, китмәклеккә, үттеләр, берлеккә* һ.б.) берәр хәреф кенә язылган. Киресенчә, артык хәрефләр өстәп язылган мисаллар да бар. Әйтик, «күңел» сүзен «күңлүл», «зиндан» сүзен «заендан» дип һәм бүтән шундый хаталар очрый. Кайбер урында бер үк сүз ике мәртәбә кабатлап язылган. Мәсәлән, «Береккәннәр сыйфаты» әсәренең 39 нчы бәйтендә Заһид сүзе ике мәртәбә язылган. Текстлардагы сүзләрдә йомшак «г» хәрефе һәр очракта да ک (кәф) хәрефе белән белдерелгән. Тәгаен «п» хәрефе булырга тиешле сүзләрдә дә аның урынына «б» язылган. Мәсәлән, фарсы телендәге «пошт-пәнаһ» сүзе кульязмада «бошт-бәнаһ» дип бирелгән.

Күрсәтеп үтелгән шушы палеографик үзенчәлекләрне һәм хаталы-ялгыш язуларны искә алганда, поэмаларны күчереп язган кешенең әсәр текстларын берникадәр үзгәрешләргә дучар иткәнлеге аңлашыла. Димәк, күчерүче тарафыннан кайбер сүзләрнең һәм кушымчаларның төшереп калдырылуы нәтиҗәсендә, поэмаларның шигъри-ритмик төзелешендә кытыршылык килеп чыккан. Шул сәбәпле Х.Миңнегуловның «Мәүла Колый бу әсәрләрен, күрәсең, яшьрәк чакта, әдәби тәҗрибәсе азрак вакытта иҗат иткәндер»[39] дигән фикере ашыгыбрак әйтелгән дияр идек. Чөнки бу очракта без поэмаларның автор каләменнән чыккан төп нөсхәсе белән түгел, ә күчерелмә варианты белән эш итәбез.

Әмма мондый текстологик ваклыклар Мәүла Колый поэмаларының әһәмиятен һич тә киметми. Чөнки бу кульязма җыентык – әдипнең күләмле әсәрләре теркәлгән, хәзергә фәнгә билгеле булган бердәнбер язма истәлек. Ә текстлардагы кайбер бәхәсле мәсьәләләр әсәрләрнең яңа күчерелмәләре табылган очракта һәм чагыштырып өйрәнү нәтиҗәсендә генә ачыкланырга мөмкин.

Бу җыентыкта Мәүла Колый поэмаларының:

– хәзерге татар алфавитына транслитерация элементлары кушылган текстлары;

– хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчермәләре;

– кульязма факсимилесе туплап бирелде. Шулай ук Мәүла Колый поэмалары теркәлгән кульязма җыентыкка тасвир һәм М.Госмановның «Тагын бер әдәби ачыш» мәкаләсен урнаштырдык.

---

[39] Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Әдәбият... – Казан: Мәгариф, 1998. – Б. 156.

# ПОЭМАЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

## [БЕРЕККӘНЛӘР СЫЙФАТЫ]

*62а кәгазь*

Кил, нигяр[1], бу дөнйаны қуйсақ кәрәк,
Ахирәт әсбабене қорсақ кәрәк.

Кил, имди бән бу дөнйадин бизәлем,
Тағға[2] барып мәсҗид-саумәға[3] төзәлем.

Ғәүрәт[4] әйде: «Дыңла сүзүм, әй, әри,
Андағ иргә ихлас кәрәк, пакь-ари[5].

Ихлас илә һәр эшни оталмазсән[6].
Ихласыңны Хақ илә тоталмазсән.

Кил, торалым ил эчендә тавағыйә
Ихлас булса, һәрқайда булмаз хата».

Ире диде: «Хақ йулы – хәлвәт[7] улур,
Хәлвәтдә тағәт[8] қыйлан Хақны булур»[9].

*62б кәгазь*

Диде ғәүрәт: «Китәр ирсәң тағ сари[10],
Хәлвәт улса, адәм йөрмәз ул йари[11]».

---

[1] *нигяр* – гүзәл.
[2] *тағға* – тауга.
[3] *мәсҗид-саумәға* – гыйбадәтханә.
[4] *ғәүрәт* – хатын.
[5] *пакь-ари* – пакь, ару.
[6] *оталмазсән* – оталмассың.
[7] *хәлвәт* – аулак.
[8] *тағәт* – гыйбадәт, намаз.
[9] *булур* – табар.
[10] *тағ сари* – тауга таба.
[11] *ул йари* – ул тарафка.

Дорды[12] Заһид, китделәр ире-хатун
Телләрендә йад итеб Тәңре атын.

Бардылар тағға йәнә хәлвәт сари
Хайван, адәм күп гизмәз ул тағ йари.

10 Ул тағ үзрә төзделәр мәсҗид-һөжрә[13]
Тағәт кыйлу[п] гомерләрен кичерә.

Дордылар Хақ әмрилә, қыйлд[ы] эши,
Күңүлләрендин чыкды дөнйа тәшвиши[14].

Дорды анлар ул саумәғида алтмыш йыл,
Рузә, намаз қыйлыб булды Хақға қол.

Алтмыш йыл имди тәмам булмушында,
*63а кәгазь* Һич хатасыз Хақға бетүб тормушында

Килде Иблис, монларга итеб вәсвәсә,
Монларның Хақға барур йулун кисә.

15 Заһидның фикеренә диде: «Қырлара вар,
Күңлеңездин китсен ул туғ-у-ғобар[15].

Заһид бу фикере күңелә алыб
Ғәүрәтенә әйде андин сүз салыб:

«Йөр чықалым, йаланларда йөрәлем,
Раузаларда[16] төрлүк[17] қошлар күрәлем,

---

[12] *дорды* – торды.
[13] *мәсҗид-һөжрә* – кечкенә мәчет.
[14] *дөнйа тәшвиши* – дөнья мәшәкате.
[15] *туғ-у-ғобар* – тугъ сүзе – буйсынучанлык, кыршау, алка мәгънәсендә; *гобар* – томан, караңгылык. *Тугъ-у-гобар* – монда: буйсынучанлык караңгылыгы (ягъни: томаналык).
[16] *рауза* – гөлбакча, чәчәклек.
[17] *төрлүк* – төрле.

Күрәлем нәбатларның[18] гөлләрен,
Ғашиқында зикер қыйлан[19] былбылларын».

Ғәүрәт әйде аңа: «Әй, Заһид!
Хақ эшендә тормаға қыйлдың ғәһед[20],

*63б кәгазь* Гизмәклекдә төрлүк нәрсә күрәсен,
Дөнйаның бер ишенә әүрүләсен».

Диде Заһид: «Йөр чықалым гизмәгә,
Сәйер қыйлыб[21] күңүл керен йазмаға».

Чықдылар, қыры-йазы[22] гизделәр,
Сәйер қыйлыб күңүлләр[ен] дөзделәр[23].

Гизә-гизә көнләре кичә булдый,
Намаз дигәр[24] вақти бер шәһәрә килди.

Туқтадылар анда бер чишмә сара[25],
Заһид андин нан[26] алмаға шәһәрә в[а]ра.

Варды Заһид ул шәһәр ичрә[27] керде,
Қайтмышында ғали[28] сарайы күрде.

---

[18] *нәбат* – үлән, үсемлек.
[19] *ғашиқында зикер қыйлан* – гыйшыкларын сөйләүче, мәхәббәтләрен сайраучы.
[20] *ғәһед* – вәгъдә, ант.
[21] *сәйер қыйлу* – йөрү, гизү.
[22] *қыры-йази* – «йази» – сахра.
[23] *дөзделәр* – төзәттеләр, хушландырдылар.
[24] *намаз дигәр* – икенче намаз, чираттагы намаз.
[25] *сара* – буенда.
[26] *нан* – икмәк.
[27] *ичрә* – эченә.
[28] *ғали* – биек, зур.

Ул сарай қапуғыдыр[29] сим-ү-зәрин[30],
*64а кәгазь* Ичрә қарап күрде бер маһе руйин[31].

Ул маһе руй ул шәһәрнең шаһ қызи,
Хөсен ичрә маһе табан[32] ирде үзи.

Күрде Заһид ул қызы, булду әүварә[33],
Қарамақдин китмәгә булмаз чара.

Белде: ул қыз ғашиқ булмуш үзенә,
Ул Заһидның қарады қыз йөзенә.

Көн-ай тик қоймуйур[34] Заһид йөзи,
Қыз йәнә ғашиқ булуб текде күзи.

Заһидә мән бер нишан[35] бирсәм кәрәк,
Ул нишандин Заһид кичә килсә кәрәк.

Ул бер заман бер айнәйе[36] алды кереб,
Айнәйи ачыб бақты қаршы торуб.

*64б кәгазь* Айнә сырты Заһидә, йөзү – үзенә,
Йабды айнәйе, кирү қайтты үзенә.

Йәнә чықды бер айақға[37] сув салыб,
Суыны түгүб, айақын керде алыб.

---

[29] *қапуғ* – капка.
[30] *сим-у-зәрин* – алтын-көмеш.
[31] *маһи руй* – ай кебек нурлы йөз, чибәркәй.
[32] *хөсен ичрә маһе табан* – гүзәллектә тулган айдай матур.
[33] *әүварә* – бер нәрсәгә бирелеп китү.
[34] *қоймуйур* – балкый.
[35] *нишан* – вәгъдәләшү бүләге.
[36] *айнәйи* – көзгене.
[37] *айақ* – савыт.

Йәнә чықды бер нары әленә[38] алыб,
Қушты нары[39], кисте уртара йарыб.

Қыз керде кирү йәнә сарайына,
Алыб чықды йәнә бер тимән игнә[40].

Сындуруб орды йиргә игнәне:
«Ник торасын, белмәйсен сән», – дигәне.

Қыз керде сарайә, чықмады ул,
Заһид андин китмәклеккә тотты йул.

Китте Заһид[41], ғәүрәтенә қавышты,
*65а кәгазь* Нигә кичү қалмышыны сорушты.

Заһид әйде: «Күчә[42] берлә мән барай[43],
Қайтмышымда күрдүм юлда бер сарай.

Ул сарайда күрдем қараб бер маһи,
Бичара улуб, ғашиқында қыйлдым аһи».

Ғәүрәт әйде: «Аны күрүб ни йолдың,
Ни нишан күргүзде ул, ни белдең?»

Заһид әйде: «Күргүзде һәр нишанын,
Нишанында белмәдем ни дигәнен».

Хатун әйде: «Нишанын дигел мәңа,
Сыйфатыны мән әйтүб бирәм сәңа».

---

[38] *әленә* – кулына.
[39] *нар (анар)* – гранат.
[40] *тимән игнә (тибән инә)* – зур энә.
[41] Күчерүче тарафыннан бу урында Заһид сүзе ике мәртәбә язылган.
[42] *күчә* – урам.
[43] *барай* – бару, баруда.

Заһид әйде: «Бер айнә алыб чықды,
Айнәсене мәңа тотуб ачыб бақты.

Йәнә бер айақ сувы алыб чықдый
*65б кәгазь* Сәрчәдин[44], килеб аны түгүб китти.

Андин йәнә бер нары чықды алыб,
Қушды аны, бер-беренә орар йарыб.

Андин алыб чықды бер тимән игнә,
Сындыруб йиргә орды аны йәнә.

Ничә бақсам чықмады андин кирү,
Йулуму[45] тотуб киттүм сәңа сару.

Белмәдем мән аны йәнә [ни] қыйлушын,
Бу эш ичрә күңелендә нә әйтмешен»[46].

Хатун әйде: «Аны белеб нидәсен?
Белсәң, йәнә аңа нә эш қыйласын?»

Заһид әйде: «Ул маһи алды күңел,
Нишанындин нә димешен сөйләгел!»

Ғәүрәт әйде: «Андағ ирсә, килгел», – димеш[47],

*66а кәгазь* ........................................................
Илтүбән[48] анлары зинданә салды.

Заһидны ғәүрәте көтте – килмәде,
Көйүкендин чәрам-қарар[49] қалмады.

---

[44] *сәрчәдин* – пыяладан, ягъни пыяла савытта.
[45] *йулуму* – юлымны.
[46] *нә әйтмешен* – ни әйткәнен.
[47] Бу урында текст өзелә, ягъни кульязмадагы берничә бит төшкән.
[48] *илтүбән* – илтеп.
[49] *чәрам-қарар* – түземлек.

«Таң намазга килмәкде[50] Заһид мәңа.
Ник килмәде, бер бәла булды аңа?»

Заһид хатуны ул бағға[51] барды йөрүб,
Сарайдин инде дайә[52] хатунны күрүб,

Дайә әйде: «Ни кеше хатуны сән?»
Хатун әйде: «Заһидның хатуны мән».

Дайә әйде: «Булды безем йөз қара,
Бу эш ичрә ни қыйлалыйқ, ни чара?»

Хатун әйде: «Мән қыйлайын чарасын,
Китәрәйен сезнең йөзнең қарасын.

*66б кәгазь* Ни йирдә Заһидлә[53] қыз? Әйдең мәңа!
Илтеңез мәне, җәһәд[54] барам аңа».

Хатунә дайә зиндан йирен әйтте,
Ике табақ аш алыб хатун китте.

Башына ике дәстарчә[55] йабуб
Шул сағәт зинданә йитте барыб.

Зинданчыға диде хатун: «Әй, ғәзиз!
Бер сағәт[кә] мәне зинданә кергүз.

Зинданда кешем бар, аш йидерәйем[56],
Бер табақ аш сәңа йийма бирәйем».

---

[50] *килмәкде* – килмәк иде, килмәкче иде.
[51] *бағ* – бакча.
[52] *инде дайә* – хезмәтче чыкты.
[53] *Заһидлә* – Заһид илә (белән).
[54] *җәһәд* – тиз.
[55] *дәстарчә* – яулык, бөркәнчек.
[56] *йидерәйем* – ашатыйм.

Зинданчы әйде: «Сүзүңне тыңлайым, хуш».
Таш тик күңүл йомшатқан бер табақ аш!

Рәван[57] кереб, тиз кирү чыққыл[58] сән йәнә,
*67а кәгазь* Хан белмәсен бу эше – қурқарым йәнә».

Хатун рәван керде ичрү[59] аш алыб,
Бер дәстарчә башындин алды салыб.

Дәстарчәне ул кызның башына салыб,
Табақны қулына бирде: «Чыққыл алыб!

Зинданчыдин табақны алғыл сораб,
Хәлүәт йиргә чыққач, табақны бораг![60]

Рәван сарайыңа барғыл җәһәт,
Сүз булса, абдырама, күңелең бикүт![61]

Қыз чықты башына дәстарчә салыб,
Китте рәван зинданчыдин табақны алыб.

Бер хәлвәттә табақны салыб китте[62],
Сарайына сәламәт барыб йитте.

*67б кәгазь* Хан йәнә мәсҗиддә чаш[63] намазын қыйлыб,
Қәһр[64] илә ултурды тәхтенә килеб.

---

[57] *рәван* – тиз, шунда ук.
[58] *чыққыл* – чык.
[59] *ичрү* – эчкә, эчкәрегә.
[60] *бораг* – ташла.
[61] *бикүт* – нык бул, тыныч бул.
[62] *салыб китте* – ташлап китте.
[63] *чаш* – төш вакыты.
[64] *қәһр* – ачу.

Диде: «Йәллат[65], килтүрүң Заһидлә қызни,
Ник бөйлә[66] қара қыйлды безем йөзни?»

Йәллатә хандин бөйлә булгач фәрман,
Зинданә шул уқ заман барды рәван.

Зинданчыйә диде: «Тиз кер ичрү,
Заһид илә хан қызын килтүр бирү!»

Зинданчы Заһидлә хатунны бирди,
Йәллат рәван монлары алыб бардый.

Заһид илә хатун ханны күрделәр,
Хезмәт[67] илә йирә йөзүн ордылар.

Хан анда диде: «Әй, бәдбәхет хатун!
Йөз қара иттең, сақламай аталық хақын».

Хатун әйде: «Ни тигде мәндин зарар?
*68а кәгазь* Ни зарар тигсә мәндин, биргел хәбәр».

Хан әйде: «Ул бағда ни қыйлмыш сән,
Йөзеңә кара сөртүб килмешсән?»

Хатун әйде: «Әй, шаһым, булғул ата,
Кичәлекдин эшемез булды хата.

Бу ғитаб[68] бағ өчүн ирсә мәңа,
Йалбарамын Тәңре хақы өчүн сәңа.

[65] *йәллат* – җәллад.
[66] *бөйлә* – болай.
[67] *хезмәт* – «хөрмәт» мәгънәсендә. Бу сүз «Хәлял нәфәқә эстәгәнләр сыйфаты» поэмасында да шул ук мәгънәдә бирелгән.
[68] *ғитаб* – шелтә, сүгү, ачулану.

Кичә берлә йиттек қараңгы булуб,
Шәһәрә кердек бер чишмә йақалай йөрүб.

Килә-килә бер бағ ичрә йиттек без,
Йоқу ғәләбә қыйлды[69] – анда йомдуқ күз.

Армышдин йоқлабмыз үздин[70] китеб,
Йоқлабмыз уйғаймай, таң намаз үтүб.

Йәлла[т] килеб тотты безне йоқудан,
*68б кәгазь* Диде безгә: «Йөрүңез, йиреңез – зиндан!»

Кичәлекдин эшемез хата булмуш,
Белмәдек без, бу бақча сезнең имеш.

Ул ғәйеб булды бездә, кичә өчүн
Ғәйбемез кичүр, Тәңре хақы өчүн».

Хан әйде: «Қанча[71] хәйлә идәсен,
Бу тәдбирлә[72] нәчә ирәб[73] кидәсен?»

Хатун әйде: «Безе монча[74] идәсен,
Бағығыза кермеш өчүн дотасын?»[75]

Хан диде кем дийә дурығ[76] сүзи:
«Сән безем қара қыйлдың йөземүзи!»

---

[69] *ғәләбә қыйлды* – җиңде.
[70] *үздин* – һуштан.
[71] *қанча* – күпме.
[72] *тәдбирлә* – ният белән.
[73] *нәчә ирәб* – ничек җаваптан качасың.
[74] *монча* – болай.
[75] *дотасын* – тотасың.
[76] *дуруғ* – тугры.

Хатун әйде: «Нә эш булды бу ара,
Нә зарарым тигеб[77] йөз булды қара?»

Хан әйде:«Заһид илә тотулуб
*69а кәгазь* Ошбу йиргә килебсән, қара йөз булуб.

Хатун әйде: «Шәриғәттә мондағ[78] эш булса,
Үз хәләле берлә тотылуб ханлара килсә...»

Хан әйде: «Ирмәсмүсән[79] минем қызым,
Йуқ ирсә ғәләтмүдүр[80] минем сүзүм?»

Хатун әйде: «Мән бу Заһид хәляли[81],
Сәнең қызың ирмәзмән[82], белгел бәли![83]»

Хан әйде: «Йөзеңне ачқыл, күрәйен,
Бу Заһидның хәлале ирсәң – беләйен».

Хатун анда чадурун ачды заман,
Хан күрүб ошбу эшдин қалды хәйран.

Хан әйде йәллатә: «Нидүр бу халь?»
Йәллатның сүз димәгә қалмады мәҗаль[84].

Хан қызына кеше изеде[85] белмәгә,
*69б кәгазь* Сарайында бары-йуқын күрмәгә.

---

[77] *тигеб* – тиеп.
[78] *мондағ* – мондый.
[79] *ирмәсмүсән* – түгелме син.
[80] *ғәләт* – ялгыш.
[81] *хәляли* – хатыны.
[82] *ирмәзмән* – түгелмен.
[83] *бәли* – шулай, дөрес.
[84] *мәҗаль* – көч, куәт.
[85] *изеде* – җибәрде.

Сарайында күрделәр ул дәм[86] қызи,
Қаралықдин йуылды ханның йөзи.

Хан йәллатә диде: «Мондағ мине хәҗил итдең[87],
Имди сән үз башыңа үзүң йитдең».

Хан бойырды – йәллате санын кистеләр,
Һәр санына дәрвазаға[88] астылар.

Заһиддин китте йәнә монча михнәт,
Хан Заһидә күб бирде мал-ғәнимәт[89].

Ул шәһәрдин киттеләр йула кереб,
Соумәғасенә йиттеләр йәнә барыб.

Йәнә алтмыш йыл қыйлдылар ғибадәт,
Көндүзен рузә тотыб, төнлә – тағәт.

Ғөмерләре ахыр улды – үттеләр,
*70а кәгазь* Дөнйа-ахирәт морадына йиттеләр.

Берекмәкдин итте анлар монча эш,
Береккәнләр асан[90] булыр йаз вә қыш.

Ғакил[91] адәм берегеб берлек қыйла,
Хақ рәхмәте берлеккә йақын була.

Кил, әй, мөэмин, берегеб қыйл һәр эши,
Хақдин рәхмәте булса[92] кәрәк ул кеши.

---

[86] *дәм* – вакыт, чак.
[87] *хәҗил итү* – оятлы итү.
[88] *дәрваза* – капка, шәһәр капкасы.
[89] *ғәнимәт* – бүләк.
[90] *асан* – имин, тыныч.
[91] *ғақил* – акыллы.
[92] *рәхмәте булса* – рәхмәт тапса.

Береккәнләр сыйфатын әйдем сезә,
Береккән эш асандыр сезә-безә.

Хак рәхмәте берлекдә хасил ула,
Берегеб тағәт қыйлан рәхмәт була.

Безләрә тәүфиқ рузи[93] қыйлғыл сәнә,
Қолларыңа, Изем[94], сән пошт-пәнаһ[95].

Тәүфиқ теләб йығларам сәндин өмид,
Рәхмәтең пәраван[96] сәнең, қыйлма нәүмиз.

*70б кәгазь*

Тәүфиқ биреб күргүз хақ йулларыңны,
Рәхмәтлеккә йарлықа қолларыңны.

Әй, Ходайа, ғасый[97] җафи Мәүля Қолый,
Рәхмәтеңлә сән биргел қоллуқ йулый.

Рәхмәтеңдин нә өмид[98] қыйлмағанны,
Рәхимсен сән, йарлықағыл сән аны.

Җөмләләри[99] йарлықаған сән Кәрим,
Ғәйебләрне йабқычы Ғәфү, Рәхим.

---

[93] *рузи* – ризык, өлеш, язмыш.
[94] *Изем* – Тәңрем.
[95] кулъязмада *«бошт-бәнаһ»* рәвешендә ялгыш язылган – таяныч, терәк, яклаучы (*пошт* – арка, терәк; *пәнаһ* – яклау).
[96] *пәраван (*дөресе: *фәраван)* – мул, бай, чиксез.
[97] *ғасый* – гөнаһлы.
[98] *нә өмид* – өметсез.
[99] *җөмләләри* – барчаларны.

*70б кәгазь*

# ХӘЛЯЛ НӘФӘҚӘ ЭСТӘГӘНЛӘР СЫЙФАТЫ

Бер нурындин йаратты Хақ Әфрасиаб[1]
Ул үзе бер шаһ иде, халқы ғораб[2].

Мөэтәфикят[3] мәқами йире[4] аның,
Бер ғәзиз қолы иде бер Ходайның.

*71а кәгазь*

Сулары иде бер дәрйа – Урқан Өгүз,
Башында Әфрасиаб, тамағы диңез.

Башындин тамағына өч айлық йул,
Тамағында бер шәһәрде, күб-қалын ил.

Әфрасиаб шәһәрендә бер фәқир
Тиречелек қыйлыр ирде ким-ү-хәқир[5].

Қырық йылча тиречелек қыйлды тәқи,
Һәр көнгә йарым тәңкә ирде хақи.

Һәр көнгә йарым тәңкә алур ирде,
Бу көчүм хәлял микә[н] дийер[6] ирде.

«Бу көчүм хәлял булса күрәйен,
Нә бирүрсә, Хақға қараб торайын.

---

[1] *Әфрасиаб* – Туран шаһы, Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәре геройларыннан берсе.
[2] *ғораб* – фәкыйрь, сәер.
[3] *мөэтәфикят* – борынгы кала.
[4] *мәқами йир* – торган җир, яшәгән урын.
[5] *ким-ү-хәқир* – ким вә фәкыйрь, мескен һәм түбәнсетелгән.
[6] Бу сүз кулъязмада *«дирү»* рәвешендә бозылып язылган.

Ихласлә[7] мән чөн бу эшне қыйлайын,
Көчүм қайчан хәлял булса – беләйен».

*71б кәгазь* Йарым тәңкә һәр көндә эшләб алыб,
Бақар ирде аны дәрйаға салыб.

Дир ирде: бу тәңкә хәлял ирсә,
Батмағай[8] бу дәрйаға, мәңа бирсә.

Қырық йылча салды суға көч итеб,
Һич берсе күренмәде, батыб китеб.

Қырық йыл итмешендә тиречелекдин,
Йарым тәңкә алды ул йалчылықдин.

Дәрйаға йәнә һәм салды ани:
«Хәлял ирсәң, батмаға қумаз сәни.

Батмаз ирсәң, сән мәңа булдуң хәлял,
Батыр ирсәң, сәнең өчүн йуқ мәлял»[9].

Дәрйаға батмаз улды тәңкә йәнә,
Тәңрегә қыйлды фәқир тәшәккер-сәна[10].

«Бисмиллаһ» тиб тәңкәне алды рәван,
Қалтасы[11] ичрә тәңкәне қыйлды пинһан[12].

*72а кәгазь* Көнләр ичрә ул шәһәрдә бер хужа
Урну олуғ, дәүләте кимсез, йүчә[13],

---

[7] *ихласлә* – ихлас белән.
[8] *батмағай* – батмас, батмаячак
[9] *мәлял* – әрнү, кайгыру.
[10] *тәшәккер-сәна* – рәхмәтләр, мактау сүзләре.
[11] *қалта* – акча янчыгы.
[12] *пинһан қыйлу* – яшерү.
[13] *йүчә* – югары, дәрәҗәле.

Кәрван улуб сәүдәгә китмәк теләр.
Күб халайық моңа йулдаш булдылар.

Урқан Өгүз дәрйасына ултуруб,
Кимәләргә кялә-қомаш[14] тултуруб.

Ул[15] хужаға килде ул тирече фәқир,
Йалбарыб сүзен әйде ким-ү-хәқир.

Диде: «Қотлуғ булсун сәфәр нийәтең,
Йүчә қыйлсун Хақ Тәғалә дәүләтең.

Мин фәқиргә күзеңне салырмусән,
Бер сүз дисәм, сән қабул алурмусән?»

Диде хужа: «Әй, фәқир, дигел сүзең!
Сүзеңә бу жан қорбан улсун безнең».

«Йарым тәңкә Хақ хәлял бирде мәңа,
Ул тәңкәне әманәт бирәм сәңа».

*72б кәгазь* Хужа диде: «Хуш, фәқир, дотам сүзең.
Бу тәңкәдин морадың айгыл[16] үзең!

Әманәтне бирдең мәңа, ни алайын,
Мән сәңа ни кирәген нә беләйен?»

Әйде фәқир: «Бу тәңкәне сән белгел,
Хакына һәр нә тигәр, алыб килгел!»

Ул хужа чөн Тәңренең хақын хақлар,
Ул тәңкәне малына қушмай сақлар.

---

[14] *кялә-комаш* – тукымалар *(кялә* – товар; *комаш* – кызыл мал).
[15] Кулъязмада *«ул»* сүзеннән соң *«қужа»* сүзе артык язылган.
[16] *айгыл* – әйтеп бир.

«Фәқир мәңа бирде моны әманәт,
Қийамәт көн булмасын тир[17] йаман ат».

Урқан Өгүз тамағына ирделәр[18],
Андағ бер олуғ шәһәр күрделәр.

Ханына керде анлар тәталлиға[19] алыб,
Хан монлара хезмәт[20] итте баш салыб.

[Йәнә] кәрван өч кичә-көндүз кичеб,
Хан кашында җөмләсе йийеб-эчеб...[21]

[17] *тир* – дир, диер.
[18] *ирделәр* – ирештеләр, җиттеләр.
[19] *тәталлиға* – бик зур теләк белән, шатланып.
[20] *хезмәт* – «хөрмәт» мәгънәсендә. Бу сүз «Береккәннәр сыйфаты» поэмасында да шул ук мәгънәдә бирелгән (кара: 67 нче астөшермә).
[21] Бу урында, кульязманың соңгы бите булу сәбәпле, текст өзелә.

# ПОЭМАЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ ЮЛГА-ЮЛ КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

## БЕРЛӘШКӘННӘР СЫЙФАТЫ

1 Йә, гүзәл, бу дөнья мәшәкатен ташлыйк,
Ахирәтебез өчен хәзерләник.

Инде мин бу дөньядан бизәм,
Тауга барып мәчет-алачык төзим.

Хатын әйтте: «Тыңла сүзем, әй, ир,
Андый иргә ихлас һәм пакь исем кирәк.

Ихлас белән һәр эшне оталмассың,
Ихласыңны Хак белән тоталмассың.

5 Торыйк халык эчендә иректә,
Ихлас булсаң, кайда да булмас хата».

Ире диде: «Хак юлы – ялгызлык булыр,
Ялгыз гыйбадәт кылучы Хакны табар».

Диде хатын: «Китәр булсаң тау якка,
Аулак булса, адәм йөрмәс ул якка».

Торды Заһид, киттеләр ир һәм хатын
Телләрендә яд итеп Тәңре атын.

Бардылар тауга – анда аулакта
Хайван, адәм күп йөрми ул тау якта.

10 Ул тауда төзеделәр мәчет-алачык
Гомерләрен кичерделәр гыйбадәт кылып.

Тордылар Хак әмере белән, кылып эшен,
Күңелләреннән чыкты дөнья тәшвише.

Торды алар ул алачыкта алтмыш ел,
Ураза, намаз кылып булды Хакка кол.

Алтмыш ел инде тәмам булганда,
Һич хатасыз Хакка бирелеп торганда,

Килде Иблис, боларга итеп вәсвәсә,
Боларның Хакка барыр юлын кисә.

Заһидка ул диде: «Кырларга бар,
Күңелегездән китсен ул томаналык.

Заһид бу фикерне күңеленә алып
Хатынына әйтте аннан сүз салып:

«Йөрергә чыгам, яланнарда йөрим әле,
Бакчаларда төрле кошлар күрим әле,

Күрим үлән-үсемлек гөлләрен,
Гашыйк булып сайрашкан былбылларын.

Хатын әйтте аңа: «Әй, Заһидым!
Хак эшендә торырга вәгъдә кылдың,

Йөргән чакта төрле нәрсә күрерсең,
Дөньяның бер ишенә әверелерсең».

Диде Заһид: «Йөрергә чыгам, гизәргә,
Сәяхәт кылып күңел керен язарга».

Чыктылар, кыр-сахраны гизделәр,
Сәяхәт кылып күңелләрен күрделәр.

Гизә-гизә көннәре узып кич булды,
Намаз вакытында болар бер шәһәргә килде.

Туктадылар анда бер чишмә буенда,
Заһид аннан икмәк алырга шәһәргә бара.

Барды Заһид, ул шәһәр эченә керде,
Кайткан чакта мәһабәт сарай күрде.

Ул сарайның капкасы көмеш-алтын,
Эченә кереп күрде бер гүзәлен.

Ул ай йөзле шул шәһәрнең шаһ кызы,
Гүзәллеге тулган айдай иде үзе.

Күрде Заһид ул кызны, таң калды,
Карап тора, китәргә юк чарасы.

Белде: ул кыз гашыйк булды үзенә,
Ул кыз карады Заһидның йөзенә.

Кояш-айдай балкый Заһидның йөзе,
Кыз янә гашыйк булып текәде күзе.

Заһидка мин бер бүләк бирсәм кирәк,
Ул бүләкне Заһид кабул кылса кирәк.

Ул бер заман бер көзгене алды кереп,
Көзгене ачып карады каршы торып.

Көзге арты Заһидка, йөзе – үзенә,
Япты көзгене, кире кайтты үзенә.

Янә чыкты бер савытка су салып,
Суын түгеп, савытын керде алып.

35 Янә чыкты бер җимеш кулына алып,
Кушты аны, кисте урталай ярып.

Кыз керде кире янә сараена,
Алып чыкты янә бер зур инә.

Сындырып ташлады җиргә инәне:
«Ник торасың, белмисең син», – дигәне.

Кыз керде сарайга, чыкмады ул,
Заһид аннан китүгә тотты юл.

Китте Заһид, хатыны белән кавышты,
Нигә кичегүен хатыны сорашты.

40 Заһид әйтте: «Урам буенча мин барышлый,
Кайткан чакта күрдем юлда бер сарай.

Ул сарайда бер гүзәлне күрдем,
Бичара булып, гашыйк булып «аһ» дидем.

Хатын әйтте: «Аны күреп ни йолдың,
Ни бүләк күрсәтте ул, ни белдең?»

Заһид әйтте: «Күрсәтте һәр бүләген,
Бүләге белән белмәдем ни дигәнен».

Хатын әйтте: «Бүләкләрен әйт миңа,
Сыйфатын мин әйтеп бирәм сиңа».

45 Заһид әйтте: «Бер көзге алып чыкты,
Көзгесен миңа тотып ачып бакты.

Янә бер савыт су алып чыкты
Пыяладан, килеп аны түгеп китте.

Аннан янә бер җимеш чыкты алып,
Кушты аны, бер-беренә орды ярып.

Аннан алып чыкты бер зур инә,
Сындырып җиргә орды аны янә.

Күпме көтсәм дә чыкмады кире аннан,
Юлымны тотып киттем синең янга.

Белмәдем мин аны янә ни кылганын,
Бу эш белән күңеленнән ни әйткәнен».

Хатын әйтте: «Аны белеп нитәсең?
Белсәң, янә аңа ни эш кыласың?»

Заһид әйтте: «Ул гүзәл алды күңел,
Бүләкләре белән ни дигәнен сөйләп бир!»

Хатын әйтте: «Андый булсаң, кил», – дигән[*],

..................................................
Илтеп аларны зинданга салды.

Заһидны хатыны көтте – килмәде,
Хәсрәтеннән түземлеге калмады.

«Таң намазына килмәкче иде Заһид миңа.
Ник килмәде, бер бәла булды аңа?»

Заһид хатыны ул бакчага барып җитте,
Хатынны күреп сарайдан чыкты хезмәтче,

Хезмәтче әйтте: «Ни кеше хатыны син?»
Хатын әйтте: «Заһидның хатыны мин».

---

[*] Бу урында текст өзелә, ягъни кульязмадагы берничә бит төшкән.

Хезмәтче әйтте: «Булды безнең йөз кара,
Бу эш белән ни кылыйк соң, ни чара?»

Хатын әйтте: «Мин кылырмын чарасын,
Китәрермен сезнең йөзнең карасын.

Ни җирдә Заһид белән кыз – әйт миңа,
Илтегез мине, бик тиз барам аңа».

Хатынга хезмәтче зиндан урынын әйтте,
Ике табак ризык алып хатын китте.

Башына ике бөркәнчек ябып
Шул сәгать зинданга җитте барып.

Зинданчыга диде хатын: «Әй, газиз!
Бер сәгатькә мине зинданга кертегез.

Зинданда кешем бар, аш ашатыйм,
Бер табак ризык сиңа ашарга бирим».

Зинданчы әйтте: «Сүзеңне тыңлыйм, хуш».
Таштай күңелне йомшаткан бер табак аш!

Тиз кереп, тиз кире чык син янә,
Хан белмәсен бу эшне – куркам янә».

Хатын тиз керде зиндан эченә аш алып,
Бер яулыкны башыннан алды салып.

Яулыкны ул кызның башына салып,
Табакны кулына бирде: «Чык алып!

Зинданчыдан табакны ал сорап,
Аулак җиргә чыккач, табакны ыргыт!

Ашык, бар тиз генә сараеңа,
Сүз булса, күңелең нык тот, аптырама!

Кыз чыкты башына бөркәнчек салып,
Китте тиз зинданчыдан табакны алып.

Бер аулакта табакны ташлап китте,
Сараена исән-имин барып җитте.

Хан мәчеттә көндезге намаз кылып,
Ачу белән утырды тәхетенә килеп.

Диде: «Җәллад, китер Заһид белән кызны,
Ник болай кара кылды безнең йөзне?»

Җәлладка ханнан мондый булгач фәрман,
Зинданга барды тиз-тиз шул ук заман.

Зинданчыга диде: «Тиз эчкә кер,
Заһид белән хан кызын бире китер!»

Зинданчы Заһид белән хатынны бирде,
Җәллад шундук боларны алып барды.

Заһид белән хатын ханны күрделәр,
Хөрмәт белән җиргә йөзләрен ордылар.

Хан анда диде: «Әй, бәдбәхет хатын!
Йөз кара иттең, сакламый аталык хакын».

Хатын әйтте: «Ни тиде миннән зарар?
Ни зарар тисә миннән, бирче хәбәр».

Хан әйтте: «Ул бакчада ни кылдың син,
Йөзеңә кара сөртеп килдең син?»

Хатын әйтте: «Әй, шаһым, булчы ата,
Кичәге эшебез булды хата.

Бу әрләү бакча өчен булса миңа,
Ялварамын Тәңре хакы өчен сиңа.

Кич белән җиттек караңгы булып,
Шәһәргә кердек бер чишмә буйлап килеп.

Килә-килә бер бакча эченә җиттек без,
Йокы басты да шунда йомдык күз.

Арганлыктан йоклаганбыз һуштан китеп,
Йоклаганбыз уянмый, таң намазы үтеп.

Җәллад килеп тотты безне йоклаганда,
Диде безгә: «Киттек, урыныгыз зинданда!»

Кичәге эшебез хата булган икән,
Белмәдек без, бу бакча сезнеке икән.

Ул гаеп булды бездә, кичә өчен
Гаебебез кичер, Тәңре хакы өчен».

Хан әйтте: «Күпме хәйлә итәсең,
Бу ният белән ничек borгаланасың?»

Хатын әйтте: «Безне болай итәсең,
Бакчагызга кергән өчен тотасың?»

Хан диде ки әйтеп туры сүзен:
«Син йөзебезне кара кылдың безнең!»

Хатын әйтте: «Ни эш булды бу ара,
Ни зарарым тиеп йөз булды кара?»

Хан әйтте: «Заһид белән тотылып,
Бу җиргә килгәнсең кара йөз булып.

Хатын әйтте: «Шәригатьтә мондый эш булса,
Үз хатыны белән тотылып ханларга килсә...»

Хан әйтте: «Түгелме син минем кызым,
Югыйсә, ялгышмы минем сүзем?»

Хатын әйтте: «Мин бу Заһид хатыны,
Синең кызың түгелмен, бел дөресне!»

Хан әйтте: «Йөзеңне ач әле, күрим,
Бу Заһидның хатыны булсаң, белим».

Хатын анда япмасын ачкан заман,
Хан күреп бу эштән калды хәйран.

Хан әйтте җәлладка: «Бу нинди хәл?»
Җәлладның сүз әйтергә калмады әмәл.

Хан кызына кеше җибәрде белергә,
Сараенда бармы-юкмы – күрергә.

Сараенда күрделәр ул вакыт кызны,
Каралыктан юылды ханның йөзе.

Хан җәлладка диде: «Мине оятлы иттең,
Инде син үз башыңа үзең җиттең».

Хан боерды – җәлладның санын кистеләр,
Һәр санын капкаларга астылар.

Заһидтан китте янә күпме михнәт,
Хан Заһидка күп бирде мал һәм мөлкәт.

Ул шәһәрдән юлга кереп киттеләр,
Алачыгына янә барып җиттеләр.

Янә алтмыш ел гыйбадәт кылдылар,
Көндезен ураза тотып, төнлә – догалар.

Гомерләре ахыры җитте – үттеләр,
Дөнья-ахирәт морадына җиттеләр.

Бердәмлектән итте алар мондый эш,
Береккәннәр имин булыр яз һәм кыш.

Акыллы адәм берләшеп берлек кыла,
Хак рәхмәте берлеккә якын була.

Кил, әй, мөэмин, берләшеп кыл һәр эшне,
Хакның рәхмәтенә ирешә ул кеше.

Берләшкәннәр сыйфатын әйттем сезгә,
Берләшкән эш иминдер сезгә-безгә.

Хак рәхмәте берлектә хасил була,
Берләшеп гыйбадәт кылган рәхмәтле була.

Тәүфикъ насыйп кылсаңчы безләргә,
Илаһым, син таяныч-терәк колларыңа.

Тәүфыйк теләп ялварам синнән өмет,
Рәхмәтең чиксез синең, кылма нәүмиз.

Тәүфыйк биреп күрсәт хак юлларыңны,
Рәхмәтлеккә ярлыка колларыңны.

Әй, Ходаем, гөнаһлы Мәүла Колый,
Рәхмәтең белән син бир коллык юлы.

Рәхмәтеңнән өметсез кылмаганны,
Рәхимле син, ярлыкагыл син аны.

120 Барчаларны ярлыкаган син Кәрим,
Гаепләрне гафу итүче Рәхим.

# ХӘЛӘЛ БАЙЛЫК
# ТЕЛӘҮЧЕЛӘР СЫЙФАТЫ

1 Бер нурыннан Хак Әфрасиабны[*] яратты,
Ул үзе бер шаһ иде, фәкыйрь халкы.

Иске кала иде торган җире аның,
Бер газиз колы иде бер Ходайның.

Сулары иде бер дәрья – Уркан Өгүз,
Башында Әфрасиаб, тамагы диңгез.

Башыннан тамагына өч айлык юл,
Тамагында бер шәһәр иде күп-калын ил.

5 Әфрасиаб шәһәрендә бер фәкыйрь
Тиречелек кылыр иде мескен-хәкыйрь.

Кырык ел буе тиречелек кылды тагын,
Һәр көнгә ярым тәңкә иде хакы.

Һәр көнгә ярым тәңкә алыр иде,
Бу көчем хәләл микән диер иде.

«Бу көчем хәләл булса – күрим,
Ни бирсә, Хакка карап торыйм.

Ихлас белән мин бу эшне кылыйм,
Көчем кайчан хәләл булса – белим».

[*] Әфрасиаб – Туран шаһы, Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәре геройларыннан берсе.

Ярым тәңкә һәр көндә эшләп алып,
Карар иде аны дәрьяга салып.

Диер иде: бу тәңкә хәләл булса,
Батмаячак бу дәрьяга, миңа бирсә.

Кырык ел буе салды суга көч итеп,
Һич берсе күренмәде, батып китеп.

Кырык ел иткәнендә тиречелектән,
Ярым тәңкә алды ул ялчылыктан.

Дәрьяга янә һәм салды аны:
«Хәләл булсаң, батарга куймас сине.

Батмасаң, син миңа булдың хәләл,
Батар булсаң, синең өчен юк хәсрәт».

Дәрьяга батмады тәңкә янә,
Фәкыйрь шөкер-мактау кылды Тәңрегә.

«Бисмилла» дип тәңкәне шунда ук алды,
Янчыгы эченә тәңкәне яшерде.

Көннәрдән бер көн ул шәһәрдә бер хуҗа
Урыны олы, дәүләте күп, дәрәҗәле,

Кәрван булып сәүдәгә китәргә теләр.
Күп кешеләр моңа юлдаш булдылар.

Уркан Өгүз дәрьясына утырып,
Көймәләргә товар-комач тутырып.

Ул хуҗага килде ул тиречє фәкыйрь,
Ялварып сүзен әйтте мескен-хәкыйрь.

Диде: «Котлы булсын сәфәр ниятең,
Мул кылсын Хак Тәгалә дәүләтең.

Мин фәкыйрьгә күзеңне салырсыңмы,
Бер сүз әйтсәм, син кабул кылырсыңмы?»

Диде хуҗа: «Әй, фәкыйрь, әйт сүзең!
Сүзеңә бу җан корбан булсын безнең».

«Ярым тәңкә Хак хәләл бирде миңа,
Ул тәңкәне әманәт бирәм сиңа».

Хуҗа диде: «Хуш, фәкыйрь, тотам сүзең.
Бу тәңкәдән максатың әйтче үзең!

Әманәтне бирдең миңа, ни алыйм,
Мин сиңа ни кирәген кайдан белим?»

Әйтте фәкыйрь: «Бу тәңкәне син бел,
Хакына һәр ни тисә, алып кил!»

Ул хуҗа Тәңренең хакын хаклар,
Ул тәңкәне малына кушмый саклар.

«Фәкыйрь миңа бирде моны әманәт,
Кыямәт көн булмасын дип яман ат».

Уркан Өгүз тамагына җиттеләр,
Анда бер зур шәһәр күрделәр.

Ханына керде алар бик теләп,
Хан боларга хөрмәт итте баш салып.

Янә кәрван өч кич һәм көн кичеп,
Хан янында бөтенесе ашап-эчеп...[**]

---

[**] Бу урында, кулъязманың соңгы бите булу сәбәпле, текст өзелә.

# ПОЭМАЛАР ЯЗЫЛГАН КУЛЪЯЗМАНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ



کیل نکار بو دنیا قویپ باق بکرا کی
آخرت اسبابینی قودرتقا کراکی
کیل ایمدی بز بو دنیادین بزار السم
تانغ بادیب مسجد صومعه تونوب الیم
عبادت ایدب منکلا سوزده ام ار ادی
اللهغه ایرکا اخلاصی کراکی پاکی ادی
اخلاصی ایله ایشنی یوطالمزسن
اخلاصینکی حق ایله تونالمزسن
کیل توبه الیم ایل الحنده طاعته
اخلاصی یولبار قایدا بولمز خطاه
ادرید حق یولی خلوات اولور
... طاعت قیل ای حقینی بولور

*62а кәгазь.*

حیدن عورت کیتا دایرنینک قانغ سار
خلوت اولسه آدم یوزمز اول یادس
دردن نی اسید کیتدیلر دایری خاتون
تیللاریندہ یاد ایتب تنکری الهین
یادریلار دنیا غوغینہ خلوات سادی
حیوان آدم کوب یکیز مز اول قانغ یادی
اول قانع اوده ده توره دیلار مسجد الحجرہ
طاعت قیلو عمرالدین کیچیرا
دردہ دیلار حق اسمیلہ قیلد ایتشی
دو نکول لیلار رنیدین حقدین قیتیتشویشی
دری اتلار اول صومغید آلتمشی ایل
دویدہ نماد حقتلبیعع الدی شغف قول
التمشی ایل الیدی نما بولمونی شید
[illegible]

*62б кәгазь.*



*63а кәгазь.*



*63б кәгазь.*



*64а кәгазь.*


اینه بیسطلی نا ایده یوزده اودینه
یابدی اینه بیبی کیت قایطلی ادن ینه
ینه چیقدی برابا قیغ یسوق بیالب
سغدینی توکوب اباقین کیردی الیب
ینه چیقدی نادی الینه الیب
قوشلی نادی کیبیتی ادرطارا یادیب
قیز کیردی کیتدی ینه بسرا اینه
الیب چیقدی ینه بر تیمان ایکینه
بیسینده روبا اوردی برکا ایکینینی
نیک توزاپسن بلمای پیسین پسندیکانی
قیز کیردی بیسرا ینه چیقمادی ادل
دا ایدا الدین کیتمکلیکنه قوتیلی یول
کیتدی دا ایدا دا ایدا غودننه قیغوشتی
نکر کینه

*64б кәгазь.*



*65а кәгазь.*



*65б кәгазь.*



66
ایلنبان انلادین یغدانه سالیب
دایه‌دن خوردنی کوتنشی کیلمدی
کویوکیندین حرام قرار قالمدی
خاتونک ماونی کیلمکمدی دایه‌دن منکا
نیکیلمدی بر بالا بولدی بکا
دایه‌دن خاتونی اول باغه باردی یوگوروب
بیریوین ایندی دایه خاتونی کوروب
دایه ایدی نیچون خلق غونه بیسن
خاتون ایدی دایه‌نینک خاتونی من
دایه ایدی بو ادنی هم بیون قادا
بو ایشنی لحمه‌ینی قیل الیغ ینی جار
خاتون ایدی من تیلانی جار بسین
کینی دانی هم نینک بوننک قرابین

*66а кәгазь.*



*66б кәгазь.*



*67а кәгазь.*



*67б кәгазь.*



*68а кәгазь.*



دیدی بزنکا بو اوفکزنی بیلمکیز دیندان
کمیچه لیکیدین ایشمز خطا بولمیش
بلمدیکیز بز بو یاقینچه یسیزنینک ایشش
اول غایب بولدی بزداکیچه اوچون
غایبمیز کیچه تنکری حقی اوچون
خان ایدی قانچه حیله ایدا بسین
بو تدبیر له نیچه ایرا اشتیدا بسین
خاتون ایدی بز موننچه ایدا بسیق
باغچه غه کرمیش اوچون اوقاسین
خان دیدی کیمه دیا دور رخ سوزنی
بسن بز بیمه قراقیتایدنیک یودموردی
خاتون ایدی نه ایشی بولدی بو اورا
ه
نه هنر اوریسه تیکیب یوز بولدی قبرا
خان ایدی ونا هیدا ایله توقتولوب
اوشبو کیکا

*68б кәгазь.*

اوشبو رکا کیلب سن قرا یوز بولوب
خاتون ایدی شاه یر معتمد مو بذا ایش بولوب
اوز حلالی برلا توقطوب خانلاره کیلب
خان ایدی ایرسهمو هی منیم قیزیم
یوق ایرسه خلقتمو جود ومنیم سعود ذوم
خاتون ایدی منی بو وزا ایدی حلالی
سینک قیزینک ایرمزمو بلسیلک جملی
خان ایدی یوزنکی احقیده بو راکی
بو وزا ایرمزنک حلالی ایرسینک هیکالی
خاتون ایدی اجه دوزخا احد زمان
خان کوردی بو شبو شدین قالدی حیران
خان ایدی یللانه نیدور بو حال
یللانینک سوزه دیمکا قالمادی مجال
خان قیزینه کیشی یبردی بالمکا

69а кәгазь.



*69б кәгазь.*


70
دونیا آخرت مرادینه یتیشتیلار
بریکیملکینی ایتیتی انلار موحد ایشی
بریکلکانلار اهل ایمان بولور دیادو قیش
عقل آدم بر کیب برلیک قیلا
حق وحدتینی برلیکه یتقان بولا
کیل ای مومن بو دیکیب قیلای ایشی
حقیقی وحدتی بولیبه کرکان ادل کیشی
بریکانلار وصفت ایدیم هیزا
بریکلکان ایشنی کیسی اندور حق بیزا
حق وحدتی برلیکدا حاصل اولدی
بریکب طاعت قیلانی رحمت بولدی
بز الاده توفیق دونی قیلغیل سینه
قول لار دیکا ایدیم حسن بهشت بناه
توفیق تیلاب یغلارام سندین امیدار
همت ایلا شید قیلمه توفیق

*70а кәгазь.*

توفیق بر سبب بولور بو حق یوللارینکنی
رحمتنکله یارلیغه قوللارینکنی
ای خدایا عاصی جافی مونکلا قولی
رحمتینکله سن بر کیل قوللوق یولی
رحمتنکدین بنده امید قیلماغی
رحیم هم سن یارلیغاغیل سن انی
جمله لارنی یارلیغاغیل سن کریم
عاصیلارین یا بقیحی عفوق رحیم
حیل النافغوا اکثر کاژلار صغینی [illegible]
بر تورتنیدین یرطهنی خفو افراسیاب
اول اودور بر پادشاه ایدی خلقی غراب
مونکلار مقامی [illegible] یاری اتیشک
بو عزیز قتی ایدی ارضا یدنکا [illegible]
سوزلاری

*70б кәгазь.*


71

سولا دن ایدی سوز جودیا ادوغان ادکرد
باشنند اذ اسباب طماغچی دیکنیز
باشنندین طماغینه ادخ ایلتو یول
طماغیندا بر شهر دی کوب قالین ایل
اذ اسباب شهر بندا بر فقیر
هر حیلیک قیلیر ده ... یو حقیر
قریق یلچه یته حیلیک قیلهدین نفقه
هر کونکا یادیم فانکا ایردی چقی
هر کونکا یادیم فانکا الو دایردی
بو کوچوم حلال میکا دیر دایردی
بو کوچوم حلال بولسه کوداین
شهر بر وقده چقغه قراب نودلی
احلا ملا من جوه بو ایشنی قیلدایی
بو جوم اتکاف حلال بولسه ایدی

*71а кәгазь.*



*71б кәгазь.*



*72а кәгазь.*


ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ
606т.

*72б кәгазь.*

# МӘҮЛА КОЛЫЙ ПОЭМАЛАРЫ ТЕРКӘЛГӘН КУЛЪЯЗМА ҖЫЕНТЫККА ТАСВИР

Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «606 т» шифры белән саклана торган бу кулъязманың Мәүла Колый әсәрләре язылган өлеше турында кереш мәкаләдә сүз булган иде. Җыентыкның башка битләренә дә кыскача күзәтү ясап китү урынлы булыр.

Җыентыкның 1а–16а кәгазьләрендә намаз, ураза һәм җеназа тәртипләре турындагы текстлар, төрле догалар язылган.

16б–18а кәгазьләрдә – «Баб[1] йолдыз хисабы», ягъни йолдызларга нигезләнгән сүрия-гарәп календаре бирелгән.

19а–23а кәгазьләрдә «Сәгатьләр бәйаны».

24а–27б кәгазьләрдә дини-шәргый мәсьәләләр.

28а–34б кәгазьләрдә Рамазан аена багышланган төрки-татар телендәге шигъри әсәр. Сүз уңаеннан искәртеп китик, борынгырак (XIX гасырга кадәрге) татар кулъязма җыентыкларында очрый торган күләмле бу әдәби ядкәр фәнебездә өйрәнелергә лаеклы әсәр.

35–37 кәгазьләрдә төрле ырымнар язылган.

37б кәгазьдә төрки-татарча шигъри парча. Аның ике юлының да соңгы сүзләре хаталы язылган. Шул ук шигъри юллар кулъязманың 61а кәгазендә хатасыз, дөрес итеп түбәндәгечә бирелгән:

«Бәйт
Гасый[2] мән дип дәргяһендин[3] бизмәзем,
Рәхмәтендин өмидүмне өзмәзем».

38а кәгазьдә төрки-татарча һәм фарсы телендә дүрт робагый язылган. Робагыйларның төрки-татар телендәгеләре мондый:

«Әдәп үгрәнгел, әй, әһле таләб[4],
Бәс көлли сәгадәткә[5] сәбәбдүр әдәб!

---

[1] *баб* – бүлек.
[2] *гасый* – гөнаһлы.
[3] *дәргяһ* – Аллаһы Тәгалә хозуры.
[4] *әһле таләб* – шәкерт.
[5] *көлли сәгадәт* – тулы бәхет.

Шәйтан кем әдәбсез булды мәхрүм,
Адәмне күрүң, нә йиргә йиткүрде әдәб!

Наз шивә[6] берлә күңүл алдуңыз,
Ҡайгу-михнәт вә бәлайе[7] алдуңыз.
Күб вафасыздин[8] өмид вар[9] иде,
Ахыр рәхимне заиғ[10] қыйлдуңыз».

Әдәбият тарихы белгечләренә бәлки бу шигырьләр таныштыр һәм авторы да билгеледер. Әгәр билгесез булсалар, тәфсилләп тикшергәндә, ихтимал, авторы ачыкланыр.

Кулъязманың 39–42, 44б–61а кәгазьләрендә җен-пәриләргә һәм зәхмәтләргә каршы төрле сихер-тылсым догалары язылган.

42б–43 кәгазьләрдә шәргый мәсьәләләр теркәлгән.

44а кәгазьдә бу кулъязма җыентыкны Бәдшәл авылында Мортаза күчереп язганлыгы теркәлгән. Бу авыл атамасын кулъязмада Бәдшәл дигәннән тыш, Бәдшай, Бәдшәк, Бәдшан, Бәдшәле рәвешләрендә дә укырга мөмкин.

61а кәгазьдә «1754 сәнә» дигән дата, фарсы телендәге робагый, алдарак тексты бирелгән «бәйт» («Гасый мән дип...»), шулай ук кулъязманы күчерүченең исеме шигъри юллар белән теркәлгән:

«Сахибен[11] кем диб сорсаңыз «мим», «ра» вә «та» вә «за»,
Әгәр ғамил улмаз ирсә[12], улдум[13] бән һәм вә аһ ғора»[14].

61б кәгазьдә зәкят турындагы «Фи бәйане зәкят» язылган.

62а–72б кәгазьләрдә, алда әйтелгәнчә, шагыйрь Мәүла Колыйның ике поэмасы күчереп язылган.

Кулъязма җыентык, кыскача тасвирлаганда, шушылардан гыйбарәт.

---

[6] *наз шивә* – назлы (хәйләле) сөйләм.
[7] *бәлайе* – бәлане.
[8] *вафасыз* – тотнаксыз.
[9] *вар* – бар.
[10] *заиғ* – әрәм.
[11] *сахиб* – хуҗа.
[12] *ғамил улмаз ирсә* – аңлашылмаса.
[13] *улдум* – булдым.
[14] *ғора* – ялганчы.

Миркасыйм Госманов

# ТАГЫН БЕР ӘДӘБИ АЧЫШ

Тарихтагы җуелмас эзләребезне беренче нәүбәттә язма мирасыбыз тәшкил итә. Бигрәк тә рухи дөнья һәм әдәбиятыбыз тарихына караган кадерле эзләрне... Соңгы 30–40 ел эчендә генә дә байтак әдәби истәлекләрнең барлануы, җыелуы һәм рухи мираска караган яңадан-яңа сәхифәләрнең бер-бер артлы ачылу фактлары моны артыгы белән раслый. Мисалга Кол Гали, Котб, Мөхәммәдьяр, Шәмсетдин Зәки, Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла һәм тагын башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән яңа басмалар дөньяга чыгуын, ә аларның исә археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә табылган кулъязмалар нигезендә барлыкка килүен күрсәтергә мөмкин. Әйе, соңгы 30–40 ел эчендә археографик белемебезне баету юнәлешендә ирешелгән казанышларыбыз бәхәссез икән.

Мәгълүм булганча, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң элекке СССРда татар тарихына караган язма материалларны җыю, өйрәнү эшләре 1960 нчы елларда иң әүвәл Казан университетында башланган иде. Утыз елдан артык эшләп килгән һәм хәзер дә дәвам итә торган эзләнүләр нәтиҗәсендә университет китапханәсенең хәзинәлегенә – Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә – Шәрык телләрендәге гарәп язулы ун меңнән артык кулъязма саклануга тапшырылды. Шушы елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы мирасханәгә дә меңләгән яңа кулъязмалар, иске китаплар керде. Болар хакында моңарчы беркадәр язылган иде инде. Шуңа күрә бүген мин кулъязма истәлекләребезне эзләү, җыю һәм өйрәнү буенча соңгы елларда барлыкка килгән яңа үзәк хакында берничә фикер әйтергә телим. Сүз Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсендә оешкан һәм «аягына» ныклап баса башлаган яңа бүлек – Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хакында.

Дөресен әйткәндә, моннан биш-алты ел элек, әлеге бүлек оеша башлаган вакытта, шәкертләремнән бер-ике егетнең анда эшкә ур-

нашуын хуплаган хәлдә, бу яңа бүлекнең киләчәге хакында кайбер шөбһәләр дә кичергән идем. Мәсәлән: социаль һәм иҗтимагый авыр шартларда яңа бүлеккә колачларны киң җәеп эшләр өчен мөмкинлекләр булырмы? Яңа истәлекләр җитәрлек күләмдә табылмаса, егетләрнең рухлары сүрелеп калмасмы?

Бәхеткә каршы, минем әлеге шикләнүләрем артык булып чыкты. Милли китапханәнең җитәкчелеге яңа бүлек үссен өчен матди шартларны мөмкин кадәр тудыра баруга иреште; яшь фикердәш һәм сафташларым исә көннән-көн канатланып, дәртләнеп эшләүләрен дәвам иттеләр. Нәтиҗәдә, Милли китапханәдә ачылган яңа бүлекнең хәзинәсендә хәзер ике меңнән артык кульъязма һәм алты меңгә якын сирәк басма китап маясы барлыкка килде.

Яңа бүлекнең тиз арада болай тернәкләнеп китүенә китапханәдә тудырылган уңай шартларга, мөгаен, тагын бер сәбәп өстәлүен дә күрсәтергә кирәктер. Ул сәбәп, минемчә, бүлек мөдире Раиф Мәрданов җитәкләгән яшь коллективның, үз тышлыгында гына йомылып калмыйча, университеттагы коллегалары белән актив хезмәттәшлеккә керүе, экспедицион эзләнүләрне кулга-кул тотынып бергә башкарулары, көнчелек, күңел тарлыгы ише начар сыйфатлардан азат булуыннан гыйбарәт. Яшерен түгел: университет китапханәсендә байлык та күп, тәҗрибә дә зур. Мәсәлән, тарих фәннәре кандидаты, доцент Җәүдәт Миңнуллин җитәкли торган Шәрык бүлегендә хәзер 15 меңнән артык кульъязма берәмлеге саклана, ә университет археографларының эзләнү тәҗрибәләре исә утыз биш еллык...

Милли китапханәдәге яңа бүлек ирешкән казанышларның әһәмиятен анда туплана башлаган байлыкның саннарына гына кайтарып калдыру да ярамастыр. Табышлар арасында чын ачыш дәрәҗәсенә лаеклары да бар. Шуны раслый торган мисалларның берсен тәкъдим ителә торган публикациядән күрергә мөмкин. Анда сүз моңарчы иҗаты тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, дөресрәге, барланмаган, укучыларга канәгатьләнерлек күләмдә ирештерелмәгән (бәяләмәсе гел «суфый шагыйрь» дигән тамгалаудан әлләни ерак китмәгән) фикер иясе, шагыйрь Мәүла Колыйның бу көнгә кадәр билгесез кала килгән зур күләмле ике әсәре хакында бара. Төгәлрәк әйткәндә, ике поэмасы хакында. Истәлекләрнең табылу

тарихы, кульъязмаларның сакланыш сыйфаты буенча авторның кереш мәкаләсендә, кыскача булса да, шактый тулы мәгълүмат бирелгән. Табышның, яңалыкның әһәмияте хакында да дөрес күрсәтелгән. Өстәп шуны гына көчәйтеп әйтәсе килә: ике поэманың өлешчә генә килеп җитүеннән чыгып, табышның әһәмиятен кечерәйтергә нигез юк. Әсәрнең өлешләре ачылу, һичшиксез, аларның тулы текстлары табылуны да тәэмин итәчәк. Чөнки без хәзер Мәүла Колый дигән шагыйрьнең, элек уйлаганыбызча, бары «хикмәтләр» кебек кыска жанрда иҗат иткән «тар» юнәлешле шагыйрь түгел, бәлки башка жанрларда да эшләгән киң колачлы автор икәнлеген белдек. Өстәвенә, аның зур күләмле әсәрләренең эчтәлеге белән әдәби үзенчәлекләре хакында да мәгълүматыбыз беркадәре артты.

Күрсәтелгән әсәрләрнең өлешчә генә саклану кебек фаҗигале күренешкә таянып, мондый оптимистик нәтиҗә чыгаруга гаҗәпләнмик. Иң элек бер өлеше генә ачылган истәлекләрнең, шул өлешләр хакында мәгълүмат игълан ителгәч, тулырак күчермәләре табылуы татар археографиясендә шактый еш очрый торган күренеш. Мисалга элек фрагментлары, аерым өлешләре генә табылган «Ярьяр» исемле тарихи йола җырының, «Түләк-Сусылу» дастанының беренче публикацияләрдән соң күпкә тулырак һәм сыйфатлырак нөсхәләре ачылу фактларын атарга мөмкин. (Бу хакта безнең «Каурый каләм эзеннән» исемле китапның 1994 елда чыккан икенче тулы басмасыннан карарга мөмкин.) Чөнки күпләгән фактлар археографик дөньябызның суы бер дә саекмый торган олуг дәрья икәнлеген туктаусыз раслап килә. Ахыр чиктә Мәүла Колый каләменә караган өр яңа әсәрләрнең табылу факты да шул хакыйкатьне тагын бер кат исбатлап тора. Шуңа күрә мин, яшь каләмдәшемне бу мөһим табышы белән ихлас котлап, аның киләчәк эзләнүләренә тагын да зуррак уңышлар теләү белән сүземне тәмамлар идем. Ниһаять, Мәүла Колый мирасын төгәлрәк туплау, тирәнрәк өйрәнү, тулырак хәлдә киң катлам укучыларга җиткерү бурычын да алар буыны сыйфатлырак итеп башкарыр дигән өметтә калам.

Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 159–160.

## РЕЗЮМЕ

Перед вами второе издание первого выпуска из серии «Татарская археография».

Основной целью серии является публикация текстов татарских литературных, исторических и других письменных памятников, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Данный отдел является одним из сравнительно молодых подразделений библиотеки, который занимается сбором, хранением и изучением татарского рукописного наследия.

Первая книга серии «Татарская археография» включает тексты двух поэм татарского поэта XVII века Мавля Кулыя, которые известны пока в единственном списке 1754 года. К сожалению, ввиду утери некоторых страниц, тексты поэм сохранились не полностью. О первой поэме – «Береккәннәр сыйфаты» (Свойство сплочённых) можно сказать, что она сохранилась практически полностью и составляет 238 полустиший. Вторая поэма – «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» (Свойство желающих честно заработать богатство) содержит 66 полустиший.

Научная значимость этих археографических находок состоит в том, что они, во-первых, характеризуют автора как творца объёмных стихотворных жанров. Во-вторых, являются своего рода ключом для поисков более полных списков указанных поэм и других творений поэта, а следовательно, к открытию новых страниц в наследии Мавля Кулый.

Впервые информация о названных памятниках была представлена Р.Ф.Мардановым в 1995 году, а сами тексты поэм были опубликованы в 1996 году в журнале «Казан утлары». А первое издание одноимённого сборника было осуществлено в 2008 году.

Помимо текстов в данном сборнике представлены археографический обзор и палеографическое описание текстов. Тексты обеих поэм даны в переложении на современную татарскую графику и с построчным переложением их на современный татарский язык. Также представлены факсимиле рукописи и статья академика М.А.Усманова «Тагын бер әдәби ачыш турында» (Ещё об одном

литературном открытии), напечатанная впервые в журнале «Казан утлары» (1996, №10) в связи с публикацией текстов поэм Мавля Кулый.

В данном издании устранены некоторые ошибки, допущенные при первой публикации.

ЭЧТӘЛЕК

«Татар археографиясе» сериясе турында ..................................................... 3
Мәүла Колый сүзли, дуслар... ..................................................................... 9

ПОЭМАЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА КҮЧЕРЕЛМӘСЕ
[Береккәнләр сыйфаты] .............................................................................. 24
Хәлял нәфәқә эстәгәнләр сыйфаты ............................................................ 37

ПОЭМАЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ
ЮЛГА-ЮЛ КҮЧЕРЕЛМӘСЕ
Берләшкәннәр сыйфаты.............................................................................. 42
Хәләл байлык теләүчеләр сыйфаты .......................................................... 53

ПОЭМАЛАР ЯЗЫЛГАН КУЛЪЯЗМАНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ ............ 58

Мәүла Колый поэмалары теркәлгән
кулъязма җыентыкка тасвир ............................................................ 80
*Госманов М.* Тагын бер әдәби ачыш ........................................................ 82
Резюме .......................................................................................................... 85

**ПОЭМЫ МАВЛЯ КУЛЫЙ**

*(на татарском языке)*
*Изд. 2-е.*

Составитель: Р.Ф.Марданов
Оформление: Ш.К.Насыров
Корректор: М.Х.Шакирова

Басарга кул куелды 01.07.2011. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ №278.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 01.07.2011. Формат 60x84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ №278.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.